СЫНАТМАДЫК

Аграрийлар, хуҗалык җитәкчеләре елның көендергән һәм сөендергән вакыйгалары турында

> 2

ХУШЛАШУ

Татар җәмәгатьчелеге Искәндәр Биктаһировны соңгы юлга озатты

> 6

ХАТАДАН – КАМИЛЛЕККӘ

Кабул итеп алдык та эше бетте түгел, төзәтү шактый вакытны ала

> 6

МИЛЛИ АККОРД

Татарстанда яшәүче халыкларның уен кораллары турында махсус проект

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 190–191 (29157–29158) | Сишәмбе | 26 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

АЛДАГЫСЫ ӨМЕТЛЕ

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ЖУРНАЛИСТЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУДА УЗЫП БАРУЧЫ ЕЛГА ЙОМГАК ЯСАДЫ

Безгә телефонны сүндерергә ярамый! «ВТ» хәбәрчесенең: «Графигыгыз бик тыгыз. Телефонны сүндереп, рәхәтләнеп бер ял иткән чагыгыз бармы?» – дигән соравына Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шулай дип җаваплады. «Кайвакыт анда начар хәбәрләр генә түгел, яхшылары да була. Телефонны сүндерергә ярамый шул безгә, эшебез шундый. Әмма ул ял итәргә комачауламый. Буш вакыт булганда ял итәбез. Спорт белән шөгыльләнергә, кем беләндер очрашырга, каядыр барырга мөмкин», – диде Татарстан Рәисе журналистлар белән ел йомгакларына багышланган очрашуда. Традицион чарада ил-көн вакыйгалары, сөенечләр һәм көенечләр, яңа максат-бурычлар турында да сүз булды.

tatarstan.ru

Махсус хәрби операциядә катнашучы егетләргә, аларның гаиләләренә ярдәм турында

Очрашуның нәкъ менә шул хакта сөйләшүдән башлануына гаҗәпләнерлек түгел, билгеле. Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә ярдәм темасы һәр көнне кузгатылуын искәртте.

– Һәркөн бу хакта иртүк фикер алышабыз. Республика дәрәҗәсендә генә түгел, һәр муниципалитет, һәр торак пункт, һәр предприятие төрле дәрәҗәдә гуманитар ярдәм программасына җәлеп ителгән, – диде ул. – Республика шефлыгындагы шәһәрләр бар. Саклану сәнәгате комплексы тарафыннан Баш Командующий куйган бурычлар үтәлә. Мобилизацияләнгәннәргә, контракттагыларга карата куелган бурычлар контрольдә. Безгә йөкләнгән бурычларны лаеклы үтәп киләбез.

Рөстәм Миңнеханов чыгышы белән Татарстаннан булган Геройлар санының артканнан-арта баруын искәртте. Гуманитар йөк юллауда төрле компанияләр, физик затларның өлеше зур булуын да билгеләп узды.

– Махсус хәрби операциядәге кешеләребез Россия дәүләте мәнфәгатьләрен яклый. Безгә каршы торган илләр дә бар, Россиянең куәтле булуын теләмиләр. Шулай да без, бөтен Россия халкы, шул исәптән Татарстан да җиңү көтәбез, шул җиңү якынайсын өчен, бөтенесен эшлибез, – диде Рөстәм Миңнеханов.

М12 трассасы турында

Каләм ияләре узып баручы елның иң истә калган тагын бер вакыйгасы уңаеннан да сорау бирми кала алмады. Рөстәм Миңнехановның Мәскәүдән Казанга кадәр яңа ачылган М12 трассасын беренчеләрдән булып сынап каравы беркемне дә битараф калдырмады. Журналистлар белән очрашуда исә Рәис аны Татарстан өчен зур бүләк дип атады:

– Территорияне үстерүдән тыш, ул – безнең икътисадка да зур ярдәм. Аннан җилдергәндә бер сулышта Мәскәүгә барып җиткән кебек тоела. Бер светофор әсәре юк. Тыныч кына баруыңны беләсең. Бу бит – куркынычсызлык та дигән сүз. Барысы да эшли. Дүрт хезмәт күрсәтү үзәгендә дә булдым. Кибеткә керәсең, анда – туклану ноктасы, хәләл ризык, намаз уку бүлмәсе. Барлык уңайлыклар да бар. Шунда ук «Татнефть»нең өч станциясе урнашкан. Барысын карадым – барысы да эшли, барысы да уйланылган. Миңа калса, бу – бик зур бүләк.

Әлеге трассаның 142 чакрымы Татарстан аша узуны да телгә алды ул. Икенче өлеше 80–90 чакрымга сузылачак. Аның аша Чаллы белән Түбән Каманы урап узарга мөмкин булачак. Рөстәм Миңнеханов Алексеевск – Әлмәт трассасын да телгә алды.

– Аны да карап кайттым. Бик күп юл һәлакәтләре теркәлә торган катлаулы трасса. Киләсе елга ул да кулланышка тапшырылачак. Дәүләтебезнең үсешен күрсәтүче бер билге дә бу, – диде Рәис.

Кадрлар кытлыгы турында

Татарстанда инженер белгечлекләр өчен мохит тудырырга кирәк һәм бу юнәлештә эш алып барыла инде. Республикадагы кадрлар дефициты турындагы сорауга җавапны Рөстәм Миңнеханов шуннан башлады.
– Хәзер бит БДИ пәйда булды. Яшь чакта «бишле» алу җиңелрәк булган иң җайлы һәм кыска юлны сайлыйсы килә. Математика, физика, химия кебек катлаулы фәннәрне сайлаучы сирәк. Шуңа күрә без яшьләрдә инженерлык тармагына барасы килү теләге уята торган мохит тудырырга тиеш, – диде Миңнеханов.

Татарстан Рәисе фикеренчә, инженер кадрларны башкала вузларында гына түгел, әйдәп баручы оешмалар каршында да әзерләргә кирәк. Бу урында Әлмәттәге югары нефть мәктәбе каршында эшләп килүче уку-лаборатория корпусын мисалга китерде ул. Якын киләчәктә Түбән Камада да шундый ук белем оешмасы пәйда булачак.
– Уку йортлары җитештерүгә якынрак булырга тиеш. Юкса студентлар укыйлар, аннары җитештерүгә киләләр дә тәҗрибә җитеп бетмәгәнлеген аңлыйлар, – диде Рәис.

Ахыры 3 нче биттә >

Дүртенче

Татарстан тормыш сыйфаты буенча төбәкләр арасында дүртенче урынга чыккан. Узып баручы ел рейтингын «РИА Рейтинг» агентлыгы төзегән. Төбәкнең социаль-икътисадый хәлен, хезмәт базарындагы вазгыять, матди иминлек, фәнни-технологик үсеш, халыкның сәламәт тормыш рәвешенә тартылу-тартылмавын исәпкә алып булдырылган ул.

Беренче өчлеккә Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Мәскәү өлкәсе кергән. Ханты-Манси автономияле округы бишенче урынга «кунаклаган». Ә менә Ингушетия, Яһүд автономияле округы һәм Тыва Республикасы исемлекнең иң ахырында калган.

Салган баштан утырма!

Узган атнада Татарстан автоинспекторлары сәрхуш хәлдә рульгә утырган 153 йөртүчене тоткарлаган. Шуның 12се инспекторлар «кармагы»на кабат эләккән.

Дәүләт автомобиль инспекциясендә искәртеп үтелгәнчә, исерек йөртүчегә 30 мең сум күләмендә штраф яки 1,5–2 елга кадәр «права»сыз калу яный. Ә инде законны кабат бозучылар ике елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителергә (шул ук вакытта 3 елга кадәр билгеле бер вазыйфа биләү хокукы юкка чыгарыла) мөмкин.

Дәүләт автомобиль инспекциясе барлык йөртүчеләрне юл законнарын тайпылышсыз үтәргә чакыра.

Салютсыз гына була

25 декабрьдән Татарстанда янгынга каршы махсус режим башланды. Ул Яңа ел каникулы ахырына кадәр дәвам итәчәк. Шушы вакыт эчендә сәнәгать, ягулык-энергетика корылмаларыннан – 500 метр, торак-коммуналь, авыл хуҗалыгы объектларыннан, юллар, шәхси йортлар, күпфатирлы йортлардан 30 метр ераклыкка китеп кенә пиротехника әйберләрен кулланырга мөмкин. Бары тик бенгаль утларын һәм «хлопушка»ларны гына теләсә кайда кабызу-шартлату рөхсәт ителә.

Махсус режим кертелү сәбәпле, Казанда Яңа ел төнендә бәйрәм мәйданчыкларында салют атмаячаклар. Шәһәрдә яшәүчеләр махсус билгеләнгән 4 мәйданчыкка барып кына утлар очырта алачак.

Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре 29 декабрьдән көчәйтелгән эш режимына күчә. Алар тәүлек әйләнәсе эшләячәк. Коткаручылар әйтүенчә, ел саен Яңа ел бәйрәмендә янгын очраклары гадәттәге көннәрдәгегә караганда күбрәк була. Төп сәбәбе – ут белән саксыз эш итү. Барлык янгыннарның 39 проценты шуңа бәйле.



Сәламәтлек

Авырып узмасын

Татарстанда грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны кисәк арткан. Шул сәбәпле бүген республиканың дәвалау оешмалары көчәйтелгән режимда эшләргә мәҗбүр. Табиблар, озын Яңа ел ялларыннан соң авыручылар саны тагын да артачак, дип фаразлый. Елның-елында шул хәл чөнки. Чирдән саклану өчен исә гади генә кагыйдәләрне истә тотарга киңәш итә алар.

Грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны арту сәбәпле, республиканың дәвалау оешмалары көчәйтелгән режимда эшли башлаган. Казан шәһәренең сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, сырхауханә һәм стационарларда да, «ашыгыч ярдәм» хезмәтенә дә эш бермә-бер арткан. Кайбер районнардагы сырхауханәләрнең эш сәгатен дә арттырырга туры килгән хәтта.

– Өйгә табиб чакыртучылар саны да артты. Шуңа күрә табибларның хәленә кереп, кирәксә-кирәкмәсә, «ашыгыч ярдәм» чакыртмасыннар иде. Температура 37гә күтәрелүгә үк «ашыгыч ярдәм» чакыртырга кирәкми. Көн дәвамында килеп ирешкән бер генә мөрәҗәгать тә игътибарсыз калмаячак. Табиблар һәркемгә ярдәм итәчәк. Сабыр итеп көтәргә генә кирәк, – дип искәртте ул.

Бүген балалар арасында да авыручылар шактый. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина сүзләренә караганда, хәзерге вакытта республикада 93 сыйныф карантинга җибәрелгән. Аларда 2 меңнән артык бала белем ала.

– Быелның 1 сентябреннән бирле республика мәктәпләрендә 5024 бала авыру сәбәпле дәресләргә йөрмәде. Билгеле булганча, әгәр сыйныфта укучыларның 20 проценттан артыгы авыру сәбәпле укырга йөрмәсә, сыйныф карантинга җибәрелә. Хәзерге вакытта Татарстанда шундый 93 сыйныф исәпләнә. Шуларның 91е – Казанда, – дип сөйләде Любовь Авдонина.

Жаворонков сүзләренә караганда, республикада коронавируска бәйле вазгыять тотрыклы булып кала бирә. Пандемия башланганнан бирле Татарстанда 214766 кеше коронавирус йоктырган. Мәкерле чир 2010 кешенең гомерен өзгән. Быел ковидтан бер генә үлем-китем очрагы да теркәлмәгән.

Көз башланганнан бирле Татарстанда грипп йоктыруның 3631 очрагы теркәлгән. Узган елның шул ук чорында андыйлар саны 5 меңнән арткан булган. Белгечләр, Яңа ел каникулыннан соң, елдагыча, грипп белән авыручылар саны бермә-бер артачак, дип фаразлый. Бу аңлашыла да. Озын-озак яллар күрешү-очрашуларга бай була. Шул рәвешле бер-береңнән чир йоктыру ихтималы да бермә-бер арта, дип кисәтә алар.

Чирдән саклану өчен, гади генә кагыйдәләрне истә тотарга кирәк. Кеше күп җыелган урыннарга битлек кимичә чыкмаска, кулларны-битләрне һәрчак юып торырга, урамнан кергәч, борын белән авызны яхшылап чайкатырга кирәк. Бүлмәләрне җилләтеп торырга да онытмагыз.

Сүзгә-сүз

Анна КУЗНЕЦОВА, Дәүләт Думасы вице-спикеры:

Өч һәм аннан да күбрәк балалы гаилә – Россиянең киләчәге. Моны Президент та искәртте. Күп балалар табу безнең илдә һәрвакыт традиция булды, хәтта сугыштан соңгы елларда да, инфраструктура җимерелгән чорда (халык саны кимүен әйтәсе дә юк!) илдә туучылар коэффициенты 5,1 иде. Хәзер бу күрсәткеч – 1,4.

(«Парламентская газета»дан)

РОССИЯДӘ – ЭШСЕЗЛЕК

Россиядәге эшсезләр саны

2017 >	3,8 млн кеше	2021 >	3,4 млн кеше
2018 >	3,5 млн кеше	2022 >	2,9 млн кеше
2019 >	3,3 млн кеше	2023 >	2,3 млн кеше
2020 >	4,8 млн кеше		

*Росстат мәгълүматлары буенча, 2023 ел

Хезмәт дәресе кайта

Киләсе елдан мәктәпләргә хезмәт дәресләре кире кайтарылачак. Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов әйтүенчә, Президент Владимир Путин «Хезмәт», «Иминлек һәм Ватанны саклау нигезләре» фәннәренең мәҗбүри булырга тиешлеге турында законга кул куйган. «Киләсе уку елыннан хезмәт дәресләре гамәлгә кертелә. Без аңа әзерләнәбез, бүлмәләрне җиһазлауны күздә тотабыз», – дигән ул.

Министр билгеләп үткәнчә, тиешле укытучылар әзерләү (шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучылар арасыннан) күздә тотыла. Моның өчен Дәүләт мәгърифәт университетында махсус хәрби операция ветераннары-педагогларны һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны башка һөнәргә өйрәтү үзәге булдырылган.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ФЕТНӘЧЕНЕ САЙЛАУГА КЕРТМИЛӘР

Дөньядагы иң зур держаowаның сайлау елы әлегә башланмаса да, Америкада Президентлык өчен көрәш кискенләшә. Колорадо штаты кандидатлар исемлегенә Трампны кертмәү турында суд карары кабул итте. АКШ Конституциясенә 14 нче төзәтмә фетнәдә катнашкан кешеләрне сайлану хокукыннан мәхрүм итәргә мөмкинлек бирә икән. Трамп яклылар исә, 2021 елның 6 гыйнварында Капитолийны яулап алып, аздан гына яңа сайланган Байден хакимиятен бәреп төшермичә калдылар бит. Шул гамәлләр бүген Трампка каршы эшли. Әмма океан артында 24 сәгать эчендә Украина – Россия конфликтын туктатырга, Америка гаскәрләрен Әфганстандагы Баһрам авиабазасына яңадан кайтарырга вәгъдә биргән популистны сайлау алды ярышыннан читләштерү кампаниясе киңрәк җәелеп бара. Тагын 16 штат аны сайлауда катнашудан читләштерергә телиләр. Белгечләр бу тормышка ашырылса да, Трампның сайлану-сайланмау мөмкинлегенә артык тәэсир итмәячәк диләр, чөнки 17 штат болай да демократлар яклы, аларда барыбер республикачы кандидатны үткәрмәсләр иде. Американың сайлау системасы шулай корылган: анда халыкның күпчелеге яклаган кандидат җиңә алмаска да мөмкин, чөнки барысы да сайлауның икенче этабында хәл ителә. Трампны башка штатлар якласа, аның җиңүгә шансы барыбер кала. Мәсьәләнең катлаулы башка ягы калкып чыга. Әгәр сайлауда Трамп җиңсә, 17 штат сайлау нәтиҗәләрен танымаска мөмкин, Байден җиңсә, башка штатлар фетнә чыгара ала. АКШта 2020 елда BLM (аббревиатура «кара тәнлеләр гомере әһәмияткә ия» дигән мәгънә бирә) төсле революция башлап җибәргән иде бит инде. Ул җиңмәсә дә, кара тәнлеләр өстенлеге җәмгыятьтә үзен сиздерә, аларга сүз әйтү, каршы гамәлләр кылу куркыныч. 2024 ел сайлавы башланып киткән сценарий буенча барса, илдә ике Президент, ике администрация барлыкка килүе ихтимал. Бу инде тулы канлы гражданнар сугышы дигән сүз. Фараз тормышка ашачак, дип әйтергә җыенмыйбыз, шундый потенциаль мөмкинлек туа. Трампның әлегә, Югары судка мөрәҗәгать итеп, үзенең барлык штатларда да сайлану хокукын кайтару шансы бар. Эш аның сайлану-сайланмавында да түгел, америкаларның үзләре арасыннан яшьрәк һәм акылга таман булмаган бер абруйлы кандидат та күрсәтә алмауларында. Үзен бөеккә санаган җәмгыятьтә пассионарлык бетеп бара.

Трампның яңадан хакимлеккә килүеннән Европада да куркалар. Германиянең оборона министры Борис Писториус: «Әгәр Трамп яңадан сайланса, бу Европа өчен һәлакәт булачак», – дип белдерде.

Россиядә

ЯҢА УКАЗЛАР ИМЗАЛАНДЫ

15 ноябрьдә Путин Ново-Огареводагы резиденциясендә бизнес әһелләре белән очрашкан. Очрашуда олигархлар үзләренә киертелгән салым камытыннан зарланды, диделәр. Очрашуның видеоматериаллары күрсәтелмәгәч, усал телләр андый очрашуның булмавын әйтсәләр дә, без рәсми мәгълүматларга ышанабыз. Эшмәкәрләр фикере исәпкә алынган яңа указлар имзалану Кремльдә бизнес зарын ишеткәннәр дигән тәэсир тудыра. Үткән ел федераль хөкүмәт, бюджет дефициты бик зурайгач, көтелмәгән адымнар ясады. Уңышлы эшләгән бизнесның йоны тагын бер тапкыр йолкынды: казнага 305 миллиард сум акча җыеп бирергә мәҗбүр булды ул. Акчаңны табыш дип кесәгә салып куярга да өлгермисең, хөкүмәт шалт иттерә дә тартып ала. Андый хәл берәүгә дә ошамый. Олигархлар бөлмәделәр бөлүен, киресенчә, күбесенең мөлкәтләре миллиардлаган долларга үсте. Әмма кесәдән өстәмә акча чыгару аларны Путинга зарланырга мәҗбүр иткән. Әле тагын җитмәсә 2025 елның 1 октябреннән экспорт пошлиналарын сум курсына бәйләү турында документ та бар икән. Моңарчы чит илгә товар сатучылар сум курсы түбәнәйгәндә оталар иде, яңа кагыйдә аларны гигант табышлардан мәхрүм итәргә мөмкин. Салым тотрыксызлыгы нәтиҗәсендә күп кенә компанияләр инвестпроектларны туңдыра, алардан баш тарта башлаган. Путин хөкүмәткә 15 гыйнварга кадәр, бизнес әһелләре белән бергәләп, уенның даими кагыйдәләрен эшләргә әмер биргән.

Киләчәктә табышка салым ставкасы үзгәрер, бизнесның инвестиция активлыгына карап, я зуррак, я кимрәк булыр, диләр. Бизнес моңа каршы түгел. Икътисадка инвестиция ясаучыларның кимрәк салым түләве күздә тотыла.

Путин имзалаган документлар арасында офшор бизнеска кагылышлылары үзе бер блок тәшкил итә икән. Белгечләр үзгәрешләргә нигездә уңай бәя бирә, без нечкәлекләрен белмәгәнлектән, шулар бәясенә ышанабыз.

Әлегә вазгыять шундый: 2024 ел башында сәнәгать тормозга басар дип көтелә. Төп ставканы күтәрү үз сүзен шул рәвешле әйтәчәк. Германия безгә байтак санда чебеш чыгара торган йомыркалар саткан. Шулардан чебеш чыгып, үзе йомырка салырлык хәлгә җитсә, йомырка кризисы бетеп тә китәр, мөгаен. Импортны алыштырдык дип фанфаралар кагу – бер нәрсә, инкубация йомыркаларын үзең җитештерү – икенче нәрсә. Соңгысы өчен тел инвестициясе генә җитми, җиң сызганып эшләргә кирәк.

РӘСМИ ТАТАРСТАН

УНИКЕНЧЕ КУБОК

«Зенит-Казан» волейболчылары Россия Кубогын яулады. Соңгы 10 елда 9 нчы мәртәбә. Гомумән алганда, уникенче тапкыр. Якшәмбе Мәскәүдә узган финал матчында якташларыбыз 3:1 исәбе белән җирле «Динамо»ны отты.

Казан командасын бу җиңүе белән Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов котлады. Ул волейбол клубы президенты Рәфкат Кантюков, республиканың Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстанның «Динамо» физик культура һәм спорт җәмгыяте рәисе Әсгат Сәфәров, команданың баш тренеры Алексей Вербов, клуб коллективы исеменә котлау телеграммасы юллады.

«Татарстандагы барлык волейбол сөючеләр һәм шәхсән үз исемемнән «Зенит-Казан» командасын ирләр арасында волейбол буенча Россия Кубогында алтын яулаулары белән котлыйм. Бу искиткеч җиңү – һәр уенчының осталыгы һәм команданың уңышлы хезмәттәшлеге, шул исәптән еш кына күләгәдә калучылар – яхшы тренерлар штабы, оста спорт менеджерлары, бу эшкә битараф булмаган иганәчеләрнең тырышлыгы нәтиҗәсе», – диелә телеграммада. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, уртак тырышлык Казан клубының чираттагы триумфын һәм күпьеллык лидерлыгын, республиканың ил спортындагы данын расларга ярдәм итте.

Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Волейбол федерациясе президенты Фәрит Мөхәммәтшин дә «Зенит-Казан» волейбол командасы уенчылары һәм җитәкчеләренә котлау телеграммасы юллады. «Безнең егетләр киеренке көрәштә искиткеч уңышка иреште һәм тагын бер кат илебез волейболында үзләренең лидерлыгын исбатлады, – диелә баш тренер Алексей Вербов, генераль директор Илһам Рәхмәтуллин һәм директор Олег Брызгалов исеменә юлланган телеграммада. – Суперлига һәм Россия Суперкубогында җиңүдән соң, бу – безнең клубның быел өченче уңышы. Татарстан яраткан командасының матур уены, бердәмлеге белән горурлана». Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, әлеге искиткеч уңыш – тренерлар штабының тырышып эшләве, уенчыларның осталыгы һәм ихтыяр көче нәтиҗәсе.

Парламент башлыгы Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе, «Динамо-Татарстан» физик культура һәм спорт җәмгыяте рәисе Әсгат Сәфәров, «Зенит-Казан» волейбол клубы президенты Рәфкат Кантюковка да котлау телеграммалары юллады.

Йолдызларга якынрак

КФУНЫҢ АСТРОНОМИЯ ОБСЕРВАТОРИЯЛӘРЕ – ЮНЕСКО САГЫНДА

Мәгълүм булганча, Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләре ЮНЕСКО бөтендөнья мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелде. Татарстанны чираттагы җиңүе белән Мәскәүдә дә котладылар.

Республика Премьер-министры Алексей Песошин Мәскәүдә ЮНЕСКО эшләре буенча Россия комиссиясе утырышында катнашты. Утырышны Россиянең тышкы эшләр министры Сергей Лавров алып барды. Форсаттан файдаланып, республиканы чираттагы җиңүе белән котладылар.

Лавров Песошинга «Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләре» объектын ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертү турында диплом тапшырды.

– Бу – илебезнең мөһим җиңүе, фәннең дөньякүләм мәдәният мирасына керткән өлеше, – диде Алексей Песошин.

Шик юк: бу җиңү – Татарстан абруе һәм аның җитәкчеләренең бу өлкәдәге хезмәтенә дә зур бәя. Искәртеп үтик: Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов – «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме рәисе, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев исә – мәдәни мирас объектларына аерым игътибар күрсәткән шәхес.

Белешмә өчен

Татарстанда ЮНЕСКОга кергән 4 объект бар. Болар – Казан Кремленең тарихи-архитектура комплексы (2000 ел), Болгар тарихи-археология комплексы (2014), Успение соборы һәм С вияжск утрау-шәһәрчеге монастыре (2017), Казан федераль университетының астрономия обсерваторияләре (2023).

tatarstan.ru

ДУСЛЫК ЧЫРШЫСЫ

Декабрьнең иң карлы көнендә Татарстанның төрле почмакларында яшәүче балалар, бер урынга җыелып, әкият дөньясына сәфәр кылды. Республика Яңа ел чыршысы турында әле сүзебез. Ул быел ике мәртәбә булды һәм икесендә дә уку алдынгыларын, төрле фестиваль-бәйгеләрдә җиңүчеләрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов шәхсән котлады.

Быел буран бәйрәмгә комачаулый язды. Юл начар булгач, кайбер районнардан автобуслар «Татнефть-Арена»га вакытында килеп җитә алмады. Ә Рөстәм Миңнеханов: «Балаларсыз бәйрәм башлана алмый!» – дип, барысын да көтәргә кушты. Ул арада оештыручылар җыелышкан балаларның күңелен күрә торды. Татарстан Рәисе исә «Идел буеның уңышлы гаиләсе» конкурсында җиңүчеләре – Биектау районыннан Камашевлар гаиләсе һәм республиканың яшьләр берләшмәләре активистлары белән очрашып аралашты.

Быел республика Яңа ел чыршысында 7–17 яшьлек 17 мең бала катнашырга тиеш иде. Барысы да җыелып беткәч, тылсымлы бәйрәм башланды. Быел ул чын дуслык һәм хыялларга тугрылык турында иде.

– Без, олылар, сезне яратабыз һәм сезнең белән горурланабыз. Сезнең бәхетле, акыллы, сәламәт һәм лаеклы кешеләр булып үсүегез өчен барысын да эшләргә тырышабыз. Сезнең кулларда – Ватаныбызның киләчәге, – диде Татарстан Рәисе, балаларны бәйрәм белән котлап. – Белемегез, хезмәтегез һәм талантыгыз белән сез илебезнең һәм республикабызның үсешенә зур өлеш кертәсез. Тырышлыгыгыз һәм казанышларыгыз ярдәмендә Татарстан узып баручы елда бик күп бәйгеләрдә, чемпионатларда җиңү яулады.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, Татарстан инде унберенче ел рәттән Бөтенроссия укучылар олимпиадасында җиңүчеләр һәм призерлар саны буенча III урынны саклый.

– Алда безне чараларга бай һәм кызыклы ел көтә. Киләсе ел республикада Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде. Киләчәктә яңа ачышлар көтә, сезгә яңа технологияләрне үзләштерергә һәм аларны тормышка ашырырга туры киләчәк. Без исә сезгә башлангычларыгыз һәм омтылышларыгызда ярдәм итәрбез, – диде Татарстан Рәисе.

Ул шулай ук Россия Президенты Владимир Путинның 2024 елны Гаилә елы дип игълан итүен, һәр кеше өчен гаиләсенең ярдәм, таяныч булуын да искәртте.

– Киләчәк Яңа ел белән! Хыялланыгыз, алдыгызга яңа максатлар куегыз, үз-үзегезгә, көчегезгә ышаныгыз. Сез барысын да булдырачаксыз! Кадерле балалар, сез – Татарстанның киләчәге, аның якты өмете. Тырышып укыгыз, бердәм һәм дус булыгыз, – диде Татарстан Рәисе.

Республика чыршысына килгән һәр бала, елдагыча, татлы Яңа ел бүләге белән кайтып китте. Быел тәм-томнар 2024 ел символы – Аждаһа рәвешендәге букчага тутырылган иде.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры **Мәганов** Наил Өлфәт улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» IV дәрәҗә ордены** белән бүләкләнде.

АВЫР, ӘММА ӨМЕТ ЗУР

Илдар Мөхәммәтҗанов

Авыл хуҗалыгы

Салмак кына адымнар белән Яңа ел якынлаша. Ул якынайган саен елга йомгак ясыйбыз, нәтиҗәләрне барлыйбыз. Хуҗалыклар, аграрийлар да үзләрен сөендергән һәм көендергән мизгелләр турында уйлана. Ел авыр булса да, барысы да киләсе елдан яктылык һәм уңыш көтә.

Рөстәм ХӘБИБУЛЛИН, «Игенче» хуҗалыгы җитәкчесе (Арча):
– Ел тәмамланырга берничә көн бар, шуңа күрә нәтиҗәләр җыелып бетмәде әле. Ләкин, гомумән алганда, терлекчелек буенча планлаштырган эшләрне артыгы белән үти алдык. Итне һәм сөтне узган елга караганда күбрәк җитештердек, табыш белән чыгарга тиешбез, дип уйлыйм. Эшчеләрнең хезмәт хакларын ел саен 12–15 процентка арттырып барырга тырышабыз. Игенчелектә генә авырлыклар булды. Узган елгы уңышны җыеп алсак та, бәясе булмау сәбәпле, кәеф кырылды. Эшләүнең кызыгы китте. Бәясе юк, ашлык беркемгә кирәкми, сатып булмый. Сөт бәяләре дә төшеп китеп, шактый керем югалды. Җәй буе сөтне 24 сумга тапшырдык. Әле менә хәзер генә 35 сумга җитте. Тәвәккәлләп, 2147 гектарга уҗым культураларын чәчеп, мәйданнарын узган елдан бермә-бер арттырдык. Башта бик нык курыктык, чөнки коточкыч коры көз килде. Тик октябрь ахыры – ноябрь башында яуган яңгырларның файдасы зур булды. Көзге бодайлар шытымнар биреп калдылар. Кышны ничек чыгарлар, анысын инде вакыт күрсәтер.

Киләсе елдан тынычлык көтәбез. Илләребез тыныч, күк йөзе аяз булсын! Тынычлык булса, калганы буенча сынатмабыз. Утырып эшләргә техникабыз, карарга терлегебез бар, калганы барысы да үзебездән тора.

Фәргать КАМАЛИЕВ, Зәй районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы җитәкчесе:
– Мин авыл хуҗалыгында 1984 елдан бирле эшлим. Шул вакыттан бирле язын өч көн рәттән 13–14 градуска кадәр суык булганы юк иде. Тишелгән арпа, чөгендерләрне кырау сукты. 1300 гектардан артык мәйданда чөгендерне кабаттан чәчәргә туры килде. Икенчедән, 2010 елдагы шикелле корылык һәм эсселек булды. Шушы сәбәпләр аркасында көткән уңышны ала алмадык. 80 мең гектар чәчүлек җиренең 70 меңендә «Агросила» агрохолдингы эшли. Быел алар эшчеләрнең хезмәт хакларын 135 процентка арттырды. Монысы сөендерә. Сөенер өчен тагын бер сәбәп: көз ахырындагы яңгырлар тишелә алмый яткан уҗымнарга тишелеп чыгарга ярдәм итте һәм туфрак дымны җитәрлек җыеп кала алды. 17 мең гектардан артык мәйданда көзге культуралар чәчтек. Былтыргы көзге культуралар гектарыннан 35 центнер уңыш бирде. Киләсе елга да яхшы уңыш булыр дип өметләнәбез. Ноябрь җылы булды, аннан соң кинәт кенә катырып, ике-өч көн эчендә кар яуды. Монысы безнең өчен яхшыга булмады, чөнки уҗымнарның яртысына ашламаны көздән кертә идек. Табигать шартларына бәйле аны да эшләп бетереп булмады. Бернигә дә карамастан, без позитив кәефтә, чөнки туфракта дым бар.

Терлекчелеккә килгәндә, узган ел яхшы савым сыерларын Азнакай районындагы зур комплекска күчергән идек. Аңа карамастан, узган елга караганда көн саен 10–15 тоннага артыграк сөт савып алабыз. Быел без тәүлегенә 52 тонна сөт савабыз. Бер сыерга туры килә торган еллык савым күләме 660 литр булыр дип уйлыйбыз.

Мансур ШӘЙХЕТДИНОВ, агроном (Кама Тамагы):
– Быелгы ел корылыгы белән истә калачак, шуңа күрә уңыш та җитәрлек күләмдә булмады. Шулай да май башындагы яңгырларның шифасы тиеп, уңышны бераз арттыра алдык. Әгәр ул вакытта явым-төшем булмаса, бернисез калырга мөмкин иде. Шуңа күрә шушындый коры елда да мондый күрсәткечләргә ирешкәнбез икән, канәгать инде без. Тик бәяләр аермасы күңелне бик нык кыра. Чыгымнар арта, ә продукцияне сату бәясе һаман да шул килеш кала бирә. Ягулык 20 сум булганда да, керем алып булмаска мөмкин иде, хәзер ул 60 сумга күтәрелде. Кая монда рентабельлек турында сөйләп булсын?! Шуңа күрә авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләргә бик кыен. Нинди генә авырлык булса да, тормыш бер урында тормый, һаман алга бара. Яңа технологияләр кертелә, үсемлекләрне саклау чаралары яңартыла. Шуңа күрә без яхшыга өметләнеп эшлибез.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ



Наил ШӘРИФУЛЛИН

«Машиналар фетнәсе»

Ясалма интеллект, ясалма акыл, нейрочелтәрләр хакында соңгы вакытларда сүз күп сөйлиләр. Андый чакта башка килгән беренче уй: «Кеше затының үз акылы, интеллекты да әлегә ташка үлчим, ул әвәләгән ясалма зиһеннең сыйфаты нииндирәк булыр икән?» «Ясалма интеллект, аның белән мавыгу кешелекне ахыр кая илтеп чыгарачак? Файда күбрәк булачакмы аннан, әллә зыянмы?»

Ясалма зиһен, дигәндә тагын бер нечкәлекне искә алу артык булмас. Кешедә, аның акыл һәм күңел шәрифләрендә, мактанырлык дәрәҗәдә үк булмаса да, шәфкать, миһербан, игелеклек, гаделлек дигән категорияләр яши. Кешенең күңеле бар. «Машина акылы»н тырышканда тудырып була гына түгел, аны беренчел вариантларын төрле кимәл, рәвешләрдә инде ясап та киләләр. Ә күңел, хисләрне? Кешенең аны тудыра аласына шәхсән мин ышанмыйм. Ясалма интеллектның «иң-иң»нәре дә хис-тойгысыз, салкын, «металл акыллы» булачагы ачык. Нәкъ менә шул сәбәпле «Адәми затның андый тәҗрибәләр үткәрергә, андый акыл барлыкка китерергә хакы бармы?» дигән сорау да тумый калмый.

Ләкин корпорацияләр андый сорау белән баш катырмый. Ясалма интеллект тудыру буенча барган проектларга бүген миллиардлар тотыла. Җитештерүдә хәзер күпләп сәнәгать роботлары кулланыла. Аларны ясалма интеллектка керткәндә кертәләр, кертмәгәндә – юк. Ә менә операторларны, техник хезмәткәрләрне, кассирларны алыштыра алган зиһенне чын-чынлап ясалмага саныйлар һәм андый очракларның барлыгы, хәтта акрынлап артуы да мәгълүм. Чират ипләп кенә «офис планктоннары»на, ул гынамы, лабораторияләрдәге галимнәргә дә килеп җитәргә мөмкин. Саналганнар тормышка ашкан тәкъдирдә, корпорацияләрнең табышы коточкыч дәрәҗәдә артачак, диләр. Чөнки ясалма акыл булдырган технологияләр, проектлар кеше ясаганнан күпкә нәтиҗәлерәк булачак, дигән фикер яши. Аннан соң андый акылга хезмәт хакы да түлисе юк. Ягъни ясалма интеллект очрагында да безне нәфес һәм комагайлык алга әйди булып чыга. Ул затсыз сыйфатлар китергән прогрессның нинди буласын бер Ходай гына белсә беләдер.

Ясалма акыл, дип нәрсә саналырга тиеш дигәндә, бәйсез карар кабул итә белүче зиһенне шулай атау дөрестер. Мәсәлән, барыбыз да белгән катлаулыдан да катлаулы программа – Windows бар. Һәр компьютерда яшәгән, операцион система ди аталган ул «зиһен»не ясалма интеллектка әле кертеп булмый. Акыллы гамәлләр кылса да, мизгел эчендә без теләгәнне башкарып куйса да, тизлек дигәндә кешене әллә кайда калдырса да. Чөнки аның «акыл»ы тулысы белән кешегә бәйле. Башкарганнары галәмәт күп, тик ахыр чиктә ул кеше төзеп куйган алгоритмга буйсына, бәйсез рәвештә нәрсә булса да майтарырга сәләтсез. Ул алгоритм кысасыннан чыга алмый. Ягъни программа хәйран акыллы булса да, ул бары инструмент кына. Ясалма акыл, дигәндә нәкъ менә кеше заты белән бер дәрәҗәдәрәк уйлый белгән, билгеле бер дәрәҗәдә бәйсез, суверен акыл хакында сөйләү дөрестер.

Сәясәтчеләр суверенлыктан курыккан кебек, галимнәр, инженерлар да ясалма акылның бәйсезлегеннән, әлбәттә, шөлли. «Восстание машин» киносындагы кебек фетнә оештырсалар нишләрсең? Планетага хуҗа буласылары килеп, кешеләрне кыра башласалар? Яисә аларны кол итсәләр? Шуңа күрә ул өлкәдә хезмәт куючылар алдына, «кыз да булсын, буаз да булсын» дигәндәй, шактый четерекле мәсьәлә килеп баса. Әмма андый проектларны барыбер туктатырга теләмиләр. Төп шарт шундый: ясалма зиһен кеше акылы югарылыгында булып, интеллектуаль яктан аңа хезмәт итәргә, аны алыштырырга тиеш. Бер үк вакытта тулысынча аңа буйсынырга. Чөнки буйсынмый башладымы, бәла яраласын көт тә тор. Әле башка бәлаләр дә юк түгел.

«Forbes» журналы ясалма интеллект кешенең когнитив мөмкинлекләрен (уйлау сәләтен), иҗатка омтылышын юкка чыгарачак, дип кайгыра. Иртәме-соңмы, ул кеше контроленнән чыгачак, ди. Аны чүлмәктән чыккан җенгә, Пандора тартмасын ачуга тиңли. Чыннан да, кемдер сине физик хезмәттән азат итә, синең урынга тир түгә икән, билгеле бер вакыт узуга, билгеле бер мускуллар зәгыйфьләнә, атрофия кичерә башлый. Тик бу бәла чын бәла түгел әле. Кемдер синең өчен уйлаган, карар кабул иткән очракта, кеше заты үзен бераздан проблемаларны чишү, анализга бирелү, хәтта уку һәм язудан да азат итәргә мөмкин. Ә бу – кирегә, бетүгә юл, деградация дигән сүз. Аның ахыры, агач башына менеп китү, тау куышына әйләнеп кайтуга барып җитмәгәндә дә, үтә куанычсыз.

Иң гаҗәбе бәлки шундадыр: адәми зат үз аңын, интеллектын ясалма зиһенгә ирекле рәвештә бирәчәк булып чыга. Ничек дисезме? Ялкаулыгы (физик хезмәтне генә түгел, акыл хезмәтен дә яратып бетермәве), уңайлыкларга мөкиббәнлеге аркасында. Димәк, ясалма акыл иртәме-соңмы бездән өстен, безгә хуҗа булып алачак. Махсус шахмат программасының хәтсез еллар элек шахмат буенча дөнья чемпионын җиңүен искә төшерик. Кеше затлары ясалма акылга кирәк булырмы, юкмы – анысы әлегә билгесез. Ике аяклы җан иясенең җитешсезлекләре, камиллектән ерак булуы иртәме-соңмы, безне шундый хәлгә төшерәчәгендә бәлки ниндидер хаклык, хәтта гаделлек тә юк түгел микән?..

Ә бүген ясалма интеллект АКШтагы Президент сайлавында (сайлау алды технологияләрен эшләүдә) катнашачак, Голливуд киноларында ифрат та шәп махсус эффектлар тудырачак, фәнни тикшеренүләргә үз өлешен кертәчәк, эшкуарларга бизнес-проектлар ясап бирәчәк. Дөнья лабораториясе саналган Көнбатышта, ясалма зиһен дигәндә, шундый хәлләр булып ята. Планетаның төп заводы, остаханәсе саналган Кытайда, табигый ресурслар сатып яшәгән Россиядә андый мавыгулар әлегә яралгы хәлендә генә.

ЧИРАТТА – ГАИЛӘЛӘР

ИРАДА ӘЮПОВА МӘДӘНИ ЕЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘДЕ

Мәдәниятле елларның чираттагысын тәгәллибез. Быел тагын да күбрәк чаралар узган, тагын да күбрәк акча эшләнгән... Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюпова, журналистлар белән очрашып, елга йомгак ясады, 2024 елга ният-максатлар турында сөйләде.

Ел чарасы

Узып баручы елда Татарстанда җәмгысы тугыз меңнән артык мәдәни чара узды. Иң эреләрен генә исәпкә алганда килеп чыккан сан бу. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында башкача булырга мөмкин түгел кебек инде, ләкин мәдәни чараларның саны киләсе – Фәнни-технологик үсеш елында тагын да күбрәк булырга охшаган. «2024 елны исән-сау уздырып җибәрә алсак ярар иде. Отпуск турында хыялланмаска куштылар инде», – диде министр.

Ә ел йомгакларына багышланган очрашуда нибары ике чарага гына аерым тукталды ул. Һәм, министрның тел төбеннән аңлашылганча, «Татарстанның мәдәни башкаласы» белән «Яңарыш: дастанның заманча укылышы» проектлары аның «шәхси рейтинг»ында – беренче урыннарда.

– «Татарстанның мәдәни башкаласы» проекты эчке проблемаларыбызны да күрсәтте. Ә алар шактый. Әйтик, милли киемне алыйк. Бик күп коллективларның костюмнарында традицион костюмның эзе дә юк. Ә бит милли кием дә – тел. Болай дәвам итсә, бу «тел»ебезне дә югалтырга мөмкинбез, – диде Әюпова.

«Гаилә абонементы»

Үткәнне үткәндә калдырып, киләчәк турында сөйләшик. Тиздән Россия халкы Гаилә елына аяк басачак. Мәдәният министры моны «буш» урыннарыбызны «тутырыр» өчен яхшы форсат дип атады.

– Бар нәрсә дә этаплап бара. Әйтик, хәтерлисезме, яшьләребез мәдәният учакларына йөрми, дип чаң сукканда, «Пушкин картасы» эшли башлады. Хәзер инде төрле чараларга гаилә белән йөрүчеләрнең санын арттырыр вакыт. Ләкин без моңа әзер булырга тиеш. Контент кына түгел, инфраструктурасы да уйларга кирәк. Әйтик, театрга гаилә яшь бала белән килә икән, анда «Ана һәм бала бүлмәсе» булсын, – дип аңлатты Ирада Әюпова.

Министр шулай ук киләсе елдан Татарстанда эшли башлаячак «Гаилә абонементы» турында да сөйләде. Ул, гаилә белән бердәм билет алып, берьюлы берничә мәдәният оешмасына барырга мөмкинлек бирәчәк. Моның өчен махсус маршрутлар төзеләчәк. Беренчесе инде әзер, аны Татарстанның Милли музее һәм Камал театры төзегән. «Тукай һәм театр» дип аталучы экскурсия Тукай исемендәге музейда башланып, Камал театрында тәгәлләнәчәк.

Сабан туйлары

Бу юлы мәдәният министры киләсе җәйдә узачак милли бәйрәмнәргә артык озак тукталып тормады. Алай да, 2024 елда кайсы Сабан туеның кайда узачагы турында белдек. Әйтик, төрки Сабан туе – Таулы Алтай шәһәрендә, көньяк Сабан туе – Сочи шәһәрендә, Каспий Сабан туе Әстерхан шәһәрендә узар дип көтелә. Бу юлы Бөтенроссия авыл Сабан туен – Пермь краеның Барда районындагы Барда авылы, Халыкара Шахтерлар Сабан туен – Кемерово өлкәсенең Прокопьевск шәһәре, Федераль Сабан туен Йошкар-Ола шәһәре кабул итәчәк. Калининград шәһәрендә – Балтыйк Сабан туе, ә Омск шәһәрендә Халыкара Иртыш буе Сабан туе узачак.

Татарстан мәдәнияте – саннарда

>2,5 млрд сум – бюджеттан тыш керем күләме;
700 млн сум – муниципаль мәдәният оешмаларының керем күләме;
>84 млн тапкыр – ел дәвамында татарстанлылар төрле мәдәният учакларына әнә шуның кадәр барган;
45540 сум – муниципаль мәдәният оешмаларындагы уртача хезмәт хакы;
66080 сум – дәүләт мәдәният оешмаларында уртача хезмәт хакы.

tatarstan.ru

Кинофестиваль

Журналистлар биргән сораулар арасында Халыкара Казан мөселман кинофестиваленә кагылышлысы да бар иде. Атамасында «мөселман» сүзе калачакмы, юкмы? (Бу хакта инде беренче тапкыр гына бәхәсләшмиләр) «Мөселман киносы» бармы ул, гомумән?

– Фестивальнең тарихына күз салсак, ул башта «Алтын мөнбәр» дип аталган. Миңа калса, бу атама фестивальгә күбрәк туры килә. Ортодоксаль, ягъни дөрес тәгълиматны катгый яклаучылар күзлегеннән караганда, кино, нәкъ картина, фотографияләр кебек үк – хәрам нәрсә. Шуңа да минем өчен «мөселман» һәм «кино» – ялганмый торган төшенчәләр. Шуңа бу хакта уйларга кирәк. Әмма минем өчен хәзерге вакытта төп сорау – ул үзенчәлекне ничек сакларга? – дип җавап бирде Ирада Әюпова.

Сөенечләр

Йомгак урынына – Ирада Әюпованың бу елда ирешкән төп нәтиҗәгә багышлап тоткан нотыгы:

– Бу эшләр нәрсә хакына идеме? Ниһаять, хәзер сувенир белән кәсепчелекне бер үлчәүдә үлчәмиләр. «Милли эшләнмәләр арзан булырга тиеш!» – дип әйтүчеләрнең кимүе дә сөендерә. Безнең традицияләрне, традицион эшләнмәләрне туристлар алдында мактану максатыннан гына файдаланмый башлаулары да куандыра. Без гореф-гадәтләребезне дә саклап кына калмыйча, яшәү рәвешебезгә әйләндерергә тиеш. Алар – тормышыбыз нигезе.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Алдагысы өметле

<Ахыры. Башы 1 нче биттә >

Рөстәм Миңнеханов дөрес миграция сәясәте булдырырга кирәклеген дә искәртте. Аерым алганда мигрантларны эшкә әзерләргә кирәклеген ассызыклады ул. Якын арада Үзбәкстан белән шундый килешү төзергә җыеналар.

– Белгечләрне йә анда, йә өлешчә монда әзерләргә кирәк. Шул рәвешле оборона сәнәгатендә, машина төзелеше тармагында булган проблемалар да хәл ителер иде. Мисал өчен, шул ук КАМАЗ заводына гына да алдагы биш елда 19,5 мең кеше җитми. Аларны әзерләргә кирәк. Моны бер көндә генә эшләп булмый. Базарны күзәтергә, алдан күреп планлаштырырга кирәк, – ди Миңнеханов.

Идел саегу турында

Татарстан Рәисе бу уңайдан да фикерен белдерде. Елганың бүгенге аянычлы хәле аркасында миллионлаган кешенең зыян күрүен дә искәртте.

– Идел – сусаклагыч һәм электр станцияләренең шарлавыгы ул. Үлчәү бер якка авышса, кайдадыр нәрсәдер җитмәячәк. Идел, иң беренче чиратта, суднолар йөреше, эчәр су белән тәэмин итү өчен билгеләнгән. Су тирәнлеге өчен җавап бирүче хезмәтләр бер генә бурычны хәл итәргә тиеш түгел. Комплексы рәвештә хәл ителергә тиешле бурыч бу. Миңа калса, аны хәл итеп була. Ил башлыгы да шундый күрсәтмә бирде, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Һөнәрчелекне саклау турында

Узып баручы Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы Казандагы данлыклы ЦУМ бинасында халык һөнәрләре үзәге төзү хәбәре белән дә истә калачак. Бүген бу тармакның ни дәрәҗәдә саклау-яклауга мохтаҗ булуы Арчада яшәүче данлыклы читек остасы Фәридә Кәримуллинаның видеомөрәҗәгатендә аермачык чагылды. Татарстанның элек-электән һөнәрчеләргә бай булып та, аларның сафы елдан-ел сирәгәя баруга борчыла ул. «Менә шушы мирасны саклап калып, киләсе буыннарга да җиткерәсе иде», – диде Фәридә ханым. Рөстәм Миңнеханов ЦУМда көтелгән үзгәрешләрнең нәкъ менә шул максатны күздә тотуын искәртте.

– Бу мәсьәләне хәл итү өчен, без элеккеге универмаг бинасын сатып алдык. Анда сәүдә нокталары гына түгел, белем бирү секцияләре дә эшләячәк. Объект Казанның нәкъ үзәгендә, бик матур урында урнашкан. Без һөнәрчеләргә үз белем-күнекмәләрен арттыру өчен мәйдан бирергә әзер. Татарстан җитәкчелеге татарларның гына түгел, республикада яшәүче башка халыкларның мәдәни мирасын саклау юлларын да эзләүне дәвам иттерәчәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рөстәм Миңнеханов эксклюзив рәвештә «ВТ» хәбәрчесенең тагын берничә соравына җавап бирде.

:: Тышкы сәясәт – мөселман илләре белән мөнәсәбәтләр юнәлешендәге бурычлар үтәлдеме? Кылган күпсанлы эшлекле сәфәрләрегезнең нәтиҗәсеннән канәгатьме сез?

– Россия һәм мөселман илләренең фикере бүгенге дөнья үсешенә кагылышлы күп кенә мәсьәләләрдә бер-берсенә туры килә. Сәүдә-икътисад һәм инвестицияләр юнәлеше үзара хезмәттәшлекнең әһәмиятле тарафы булып тора. Ислам икътисады дөнья икътисадының мөһим өлешен тәшкил итә. Халыкара сәүдәдә аның микъдары елдан-ел арта бара.

Бүген үзара товар әйләнешен үстерү, халыкара транспорт коридорлары эшен камилләштерү һәм уртак инвестиция проектларын гамәлгә ашыру мөһим.

Ислам икътисадын үстерү юнәлешендә киләчәгебез бик өметле. Азык-төлек, туризм, медицина һәм башка өлкәләрдә хәләл индустрия актив үсеп килә. Мөселманнарга гына түгел, киңрәк аудиториягә йөз тоткан IT технологияләргә уңышлы мисаллар бар. Татарстан ислам банкингын үстерү буенча сынау төбәкләренең берсенә әйләнде. Моннан тыш, ислам дөньясы белән фән, мәгариф, мәдәният, спорт, туризм өлкәсендә хезмәттәшлекне киңәйтү юнәлешендә актив эшлибез.

Безнең башкарган эшләрне саннар яхшырак күрсәтеп бирер. 2023 елның 9 аенда Татарстанның Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре белән товар әйләнеше 4 млрд 185 млн доллар тәшкил итте. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, бу сан 2,3 тапкыр артты. Шунысы да игътибарга лаек: экспорт импорттан шактый күбрәк. Гыйнвардан сентябрьгә кадәр 3 млрд 724 млн долларлык продукция экспортка чыгарылган, ә импорт 460 млн доллар тәшкил иткән.

Быел Татарстанның Төркия, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Казахстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Иран, Тунис, Мисыр кебек дәүләтләр белән товар әйләнеше аеруча зур.

Без уңышларның мизгел эчендә яуланмаганын аңлыйбыз, шуңа күрә ислам илләре белән мөнәсәбәтләребезне максатчан рәвештә үстерә барабыз. Эшебезнең нәтиҗәләреннән минем канәгать булу-булмавым турындагы соравыгызга «юк» дип җавап бирәм. Ислам хезмәттәшлеге оешмасы дәүләтләре белән үзара мөнәсәбәтләрне үстерүнең потенциалы бик зур. Мин үзебезнең тагын да яхшырак эшли алуыбызны анык беләм. Шуңа күрә алга баруны дәвам иттерәчәкбез.

:: Соңгы арада Татарстанда бер-бер артлы почта бүлекчәләре ябыла, эшләргә кеше юк. Хат, газеталарны ике атнага бер китерү очраклары күп. Дистә еллар буе эшләгән почта системасы юкка чыгып бара, ә бу – почтаның социаль институт буларак юкка чыгуы дигән сүз. Шуның белән беррәттән Татарстан – почта бүлекләрен төзекләндерү буенча актив эш башкарган төбәк. Бу четерекле мәсьәләне, әлбәттә, ил күләмендә хәл итү кирәк. Сез аны хәл итү юлларын нидә күрәсез?

– Почта бүлекчәсе иң әһәмиятле социаль объектларның берсе булып тора, бигрәк тә авыл җирлеге өчен. Республикада 1112 почта бүлекчәсе исәпләнә, аларда 8 меңнән артык хезмәткәр эшли, шуларның 3,5 меңе авыл җирлегенә карый. Аларның хезмәте нәтиҗәсендә халык вакытлы матбугат яздыра, хат-хәбәрләр алып-җибәреп тора, акча күчерә, көндәлек кирәк-ярак товарлары сатып ала, ТКХ өчен түли, пенсияләр дә почта ярдәме белән ияләренә ирештерелә.

Россия Президенты Владимир Путин йөкләмәсе нигезендә авыл җирлегендә урнашкан почта бүлекчәләре яңартыла. Быел төзекләндерү-яңарту эшләре республиканың 22 районындагы 32 элемтә бүлегендә алып барылды. Киләсе елда бу эш дәвам иттереләчәк.

Чыннан да, бүген кадрлар мәсьәләсе аеруча катлаулы. Безгә 337 хат ташучы җитми. 106 элемтә бүлеге вакытлыча ябылган, шуларның 103е – авыл җирлегендәге бүлекчәләр. Шул ук вакытта почтальоннар өйдә хезмәт күрсәтүне дәвам иттерә, күчмә элемтә бүлекчәләре эшли. Аерым алганда, барлык пенсионерлар да үз вакытында пенсияләрен алып тора.

Әлбәттә, почта хезмәткәрләренең эштән китүендә төп сәбәп – хезмәт хакының җитәрлек булмавы. Бүген Татарстанда 2,8 мең авыл почтальоны минималь хезмәт хакыннан азрак акча ала. Хәзер аларның хезмәт хакын республикадагы минималь хезмәт хакы дәрәҗәсенә, ягъни 19 мең 565 сумга җиткерү мәсьәләсе хәл ителә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

«ҮЗЕМӘ БҮЛӘК ЯСАДЫМ»

Балтач

Балтач районының Иске Салавыч авылы кызы Айгөл Шакирҗанованың, Мәскәүдә үткән ирланд биюләре буенча ачык чемпионатта катнашып, алты алтын медаль алуын сайтыбызда хәбәр иткән идек инде. Баксаң, Айгөл әлеге конкурста җиде алтын һәм бер көмеш медаль откан икән.

:: Айгөл, сигез конкурста катнашып, сигезендә дә пьедесталга күтәрелү уен эш түгел... Үзең мондый нәтиҗә көткән идеңме соң?

– Юк, билгеле. Әле бит Казандагы ирланд биюләре буенча махсуслашкан бердәнбер «Sonas» (ирланд телендә «бәхет» дигәнне аңлата) мәктәбенә йөри, махсус укытучы-тренер белән һөнәри дәрәҗәдә шөгыльләнә башлавыма гыйнварда бер ел була. Мондый күләмле конкурсларда беренче тапкыр катнашуым. Тренерым да гаҗәпләнде, беренче тапкыр катнашып, шундый җиңүләр яулау – бик сирәк хәл, диде, әмма бик нык сөенде инде. Беренче тапкыр катнашкач, ярышка ул үзе дә минем белән барды һәм миннән дә ныграк борчылды. Аңа, үземә, якыннарыма Яңа елга бүләк булды инде ул.

Әлеге конкурска, мин дә катнашам әле, дип кенә барып булмый, аның өчен әллә ничә һөнәри баскыч сайлауларны узган, махсус категорияле укытучы-тренер белән шөгыльләнгән кеше генә катнаша ала икән. Мәнә шуны белгәннән соң Казандагы махсус мәктәпне эзләп таба да инде Айгөл һәм ялгышмый. Биредә үз эшенә фанатларча бирелгән Анастасия Дулесова кул астында, үҗәтләнеп, әлеге бию базасын, техникасын өйрәнә, үзлегеннән өйрәнгән күнекмәләрен һөнәри яктан ныгыта кыз. Тик конкурска барыр көн җиткәндә генә Айгөл агулана, аннан салкын тидерә: йөткерә, температурасы күтәрелә. Барып булмас инде, дигән уйны күңеленә дә кертми ул. Авыруның беркемгә сиздерми, поездда аның температурасы белән барганын белгәч, тренеры, әйдә, кире борылыйк, дип карый. Тик үзсүзле Айгөл: «Барырга чыкканбыз икән инде, барабыз», – ди.

Әллә конкурс барган залдагы күтәренке рух тәэсир итә – анда баруга, Айгөл барлык авыруларын оныта. «Минем чират җитә, музыканы куялар һәм мин, берни булмагандай, җиңел генә биеп чыгам... Сигез тапкырында да шулай булды. Хәтта авыл сәхнәсендә, туйларда, юбилейларда биисе булса да, борчылып бетә идем, ә монда ник бер борчылыйм. Әйтерсең, мәртәбәле комиссия алдында түгел, әйдә үзем өчен генә биим».

Ә бит барысы да әнә шул өйдә үзе өчен генә биюләрдән башлана. Кечкенәдән, видеолардан карый-карый, яңа биюләр, хәрәкәтләр өйрәнә кыз. Төрле халыклар биюләре белән башлангыч сыйныфта укыганда ук инде авыл сәхнәсенә менә. «Йолдызлык»та катнаша, «Балтач бии» дигән зурлар бәйгесендә җиңү яулый, студент булгач, «Студент язы» бәйгесендә «Органза» бию коллективы составында уңышлы чыгыш ясый.

:: Айгөл, күп төрле биюләрне соклангыч итеп биегәнеңне ишетеп түгел, күреп беләм. Ә шулай да ни өчен ирланд биюе?

– Мәктәптә укыганда, видеолар аша биюләр өйрәнгәндә, ирландлар бии торган бер шоу язмасын таптым. Аннан икенчесен карадым. Шундый зур, искитмәле шоулар иде алар. Мәнә шулардан мавыгып киттем. Аннан соң, бу биюләрнең ритмы, музыкасы ничектер күтәренкелек, күңелгә рәхәтлек бирә бит. Күпләр шулай ди. Авыл сәхнәсендә беренче тапкыр ирланд биюен биегәч тә, бик ошаттылар, нинди генә чарада катнашсам да, шул биюеңне бие әле, диләр иде. Болар барысы да роль уйнагандыр инде. Дөрес, мин барлык биюләрне дә яратып бии, дөньямны онытып өйрәнә идем. Студент елларымда да, эшли башлагач та биюне ташламадым. Үземне гел формада тоттым. Тик ниндидер бер зур конкурста, һөнәри дәрәҗәдәге конкурста катнашып, үземне сыныйсы килә иде. Шундый чыгга ашмас бер хыял бар иде... Һәм ул чынга ашты...

...Күңелеңдәге башка чынга ашмастай хыялларың да чынга ашсын, уңышлар, Айгөл!

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Ватан хакына

ИКЕ УЛЫН КӨТҮЧЕ НӘФИСӘ ХУҖИНА:

«ДОГАЛАРЫМ САКЛАП ЙӨРТСЕН»

Саба

Саба районының Юлбат авылында гомер итүче 73 яшьлек Нәфисә апа Хуҗина, махсус хәрби операциядән ике улының исән-имин кайтуын теләп, догалар кыла. Көнделендә бары тик бер теләк: уллары исән-сау кайтып, үз балаларын үзләре үстереп, тапкан малларының игелен күреп яшәсеннәр иде. Һәр иртә балаларыннан хәбәр көтеп уяна, аларны уйлап йокларга ята. Хәер, үзе әйтмешли, инде икенче елын элеккеге кебек йоклаганы, ашаганы юк аның. Ике улының кайтуын көтеп яши.

– Әле менә Фәргатем ялдан кайтып китте. Күңелгә бигрәк ямансу вакыт. Беренче тапкырдагы кебек. Өлешчә мобилизация башлангач та, улыма повестка килде. Шимбә кич иде ул. Ял көнне улым военкоматка китте. Дүшәмбе иртән аны алып та киттеләр инде. Казанда бер ай булдылар. Әллә ничә операция кичергән иде. Шуңа да китәр төсле түгел иде инде. Кире кайтарырлар әле, дип уйладым, – дип сөйли Нәфисә апа.

Фәргатенә – 44 яшь. Хатыны Эльвира белән күрше йортта гына яшиләр. Ике бала үстерәләр. Олысы – 9, кечесе 7 нче сыйныфта укый.

– Гаиләсе бик сагына улымны. Балалары: «Әти кайчан кайта?» – дип кенә торалар. Хатынына да рәхәт түгел. Әле ярый алар янәшәмдә, дим. Бар тормышыбыз уртак инде безнең. Таң атуга, улымның хәлен сорап, киленем янына керәм. Күбрәк хатыны белән элемтәдә тора ул. Миңа инде аларның исәнлеген белсәм, шул җитә, – ди Нәфисә апа. – Гаиләдә ир булмау бик читен. Мин үземне түгел, улымның хатыны һәм балаларын уйлыйм. Киленем белән икесе бергә фермада эшләделәр. Бераздан улым башка эшкә күчте. Йорт җиткереп, матур гына яшәгәндә, илдә тынычлык бетте. Фәргатем кыю йөрәкле ул. Чечняда да булып кайткан иде. Монда да гел алгы сызыкта. Аллаһы Тәгаләгә исәнлеген бирсен инде.

Фансат улыма тиздән 35 яшь тула икән. Быел май аенда ул контракт төзеп китеп барган. Кызганыч, аның гаиләсе таркалган. Матур гына башланган тормышлары җимерелгән дә куйган. Ике баласы бар икән.



– Ирем Фирдинант белән 7 бала үстердек. Бер балабыз 3,5 яшь чагында вафат булды. Бик шук иде, тик тора белмәде. Ат яратты. Яз көне, атка атланам дип, тәртәгә менеп баскан да башы белән егылып төшкән. Шулай харап булды. Алты баламны исән-сау үстердек. Бер кызым, 5 улым бар минем. 53 яше тулмаган иремне Фирдинант үлгәндә, Фансатым 2 нчедә генә укый иде әле, – дип искә ала Нәфисә апа.

Ул чакта Фәргать армиядә була. Өйдән бар кирәк-ярак белән чыгып китсә дә, Казан военкоматында ук букчасындагы бар әйберләрен алып калалар аның. Ручка белән кәгазе дә булмый, алдан хәстәрләгән конвертларына кадәр алалар. Хезмәт итәргә Сахалинга ук җибәрәләр. Алты ай бүе хәбәре килми. Ниһаять, 13 ноябрьдә, Нәфисә апаның туган көненә улыннан хат килеп төшә. «Исәнме, әни»,

– дип башланган хат тулысы белән әтиләренә багышлана. Фәргать сүз саен әтисен сорый, аңа әйтәсе сүзләрен яза. Тик кызганыч, әтиләренең вафатына алты айлап вакыт узган була инде.

– Мин ул хатны укый алмадым. Балалар кычкырып укый, еладым да еладым. Улым да без язган хатны укый алмаган. Интәшләре укып бирган. Әтисенең үлемен ишетү аңа да бик авыр булган. Балакаем, хезмәт итеп бетергәнче, әтисенең юклыгына ышанмаган. Армиядән туры зиратка кайткан. Каберен күргәч кенә, әтисез калганын кабул иткән, – ди Нәфисә апа. – Ирсез калгач, тормышым җиңел булмады. Балаларымны үстерәсе дә бар бит әле. Тырыштым, тырмаштым, көн-төн эшләдем. Әммә каяндыр ярдәм көтмәдем.

Нәфисә апаның тагын ике улына повестка килгән була. Моны ишеткәч, бөтенләй бетә ул. Инде ничекләр яшәрмен дигәндә, аларны эшеннән җибәрмичә алып калганнар. Ана күңеле бераз булса да тынычланган.

– Илдәге хәлләр бар тормышыбызны үзгәртте. Бернинди борчу белмичә, рәхәт яшәгәнбез икән. Безнең авылдан бик күп ир-егетләр – Ватан сагында. Шуларның әниләре, хатыннары белән аралашып яшибез. Бөтен Саба районында яшәүчеләр берләштек инде. Ни булса да, сөйләшбез. Берәребезнең улы элемтәгә чыкмаса, аның хәлен беләбез. Җыелы сүзләребезне кызганмыйбыз. Көтүләре бик читен. Инде яхшы хәбәрләр ишетелсен, дибез, – ди Нәфисә апа. – Берәрсеннән хәбәр булмаса, кан басымым күтәрелә башлый. Бик кайгырам. Йөрәк урыннан кузгала, калтырап тора. Шөкер, Фәргатем исән-имин үз частена барып урнашкан инде. Фансатым да хәбәрләшеп тора. Әлегә күңелем тыныч.

Берләшү дигәннән, Нәфисә апа күршесе Фәния апага рәхмәтле. Гел хәлен белеп, кереп йөри икән.

– Үз өемдә яшим. Балаларым барысы да яннарына чакыра. Әммә үз өең – үз көең инде ул. Әле бит күршедә улым гаиләсе яши. Шуңа да мин кязсы түгел. Улларым исән-сау кайтып сөендерсә, бар дөньям түгәрәкләнер иде, – ди Нәфисә апа. – Солдат әнисе дип кая гына чакырмыйлар. Концерт-театрлар да күреп кайттым инде. Дәүләттән булган хөрмәткә рәхмәт. Улларыбыз ил өчен көрәшкәндә, безне ташламыйлар. Ишле бала үстереп тә, хөкүмәттән бер ярдәм күрмәгән кешегә, хәзер болай итеп якын күреп торулары әллә ничек. Баламның гаиләсен ташламаганнарына да сөенәм. Аларга эти кирәк. Шул юклыкны сиздермичә яшәтүләренә дә ризамын. Һәр балам исән-сау булып, картлыгымда аларның тормышына сөенеп яшәсәм иде. Мин начар уйлар уйламаска тырышам. Балаларымның исән-сау кайтуына ышанам һәм көтәм дә. Аларны догаларым саклап йөртсен иде, дип телим.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Нәтиҗә

Көндәш көткәндә

«Канәгатьсезлек кичермим». Татарстанның спорт министры Владимир Леонов узып баручы елга (спорт телендә әйтсәк, сезонга) әнә шундый бәя бирде. Елны ничек тәмамлыйбыз?

ҖИҢҮЛӘР

Спортта ирешелгән уңышлар җиңүләр белән бәяләнә. Быел ул яктан уңышлы ел дияргә нигез бар инде. («Ак барс» хоккей клубының Гагарин Кубогын ота алмавын исәпкә алмаганда. Хәер, анысына кайгырмаска кушты министр. Әйтүенчә, финал ярышлары аерым фильм төшерергә лаек).

- «УНИКС» баскетбол командасы – ВТБ лигасы җиңүчесе;
- «Зенит» волейбол командасы – Суперкубок иясе, ил чемпионы;
- «Рубин» футбол командасы – Мелбет-лига чемпионы;
- «Стрела – Ак барс» регби командасы – Россия Кубогы иясе;
- «Ирбис» флорбол командасы – Россия Кубогы иясе;
- «Динамо – Ак барс» чирәмдәге хоккей клубы 22 нче тапкыр Россия чемпионы.

«ИҢ-ИҢ»НӘР

Татарстан җыелма командасы исәбендә булган спортчыларның уңышлары да сөендерә. «Иң-иң»нәр дип министр Софья Дьякова, Даниел Маринов, Ксения Задворнова, Сергей Сергеев, Диана Миронова, Вероника Кудерметова, Владислав Артемьев, Евгения Косецкая кебек яшьләребезне атады.



tatarstan.ru

Владимир ЛЕОНОВ,
Татарстанның спорт министры:
– Киләсе елда вазгыять үзгәрер дип өметләнәм. Безнең уртак бурычыбыз – спортчыларыбызга дөнья аренасына чыгу мөмкинлеген тудыру. Аларга көндәшлек җитми. Турнирларда нинди дә булса статуста чыгыш ясасыннар иде. Халыкара көндәшлек, чынлап та, аз. Башка спортчыларга да безнекеләр җитми.

СПОРТ БӘЙРӘМЕ

Быел Татарстан һәм аның башкаласында спорт сөючеләр өчен бәйрәмнәр күп булды. Әйтик, футбол буенча Россия Суперкубогы, йөзү буенча Россия Кубогы финалы, Фиджитал уеннарының сынау ярышлары, Махсус Олимпиаданың Бердәм уеннары, «Ефәк юлы» халыкара ралли узышы, спорт музее ачылышы. Барлыгы – 800дән артык республикакүләм һәм илкүләм ярышлар.

ХЫЯЛ

2024 елда да Татарстан һәм аның башкаласы шактый зур халыкара чаралар үзәге булачак. Шуларның берсе февраль – март айларында узачак «Киләчәк Уеннары» халыкара ярышы. Тарихта тәүге мәртәбә оештырыла торган бу чарага дәүләт җитәкчесе дә көтәләр. Һәрхәлдә, ил Президентының чакыру җибәргәннәр инде. Кем белә бит, бәлки...

БРИКС саммиты алдыннан Казанда «БРИКС илләренең спорт уеннары» халыкара чарасы узачак. 4–18 июнь көннәрендә 27 спорт төре буенча ярышлар каралган. Аңа кадәр спорт корылмаларын тәртипкә китереп өлгертәсе бар.

– Ярышларда биш меңгә якын катнашучы булыр дип көтелә: бу – 3 мең спортчы, шулай ук 500ләп чакырылган кунак, 2 меңләп рәсми затлар. Уеннарга 10 ил чакырулы, – диде министр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сан

- Татарстанда яшәүче халыкның **60,9** проценты физик культура һәм спорт белән шөгыльләнә. Бу – **2,15** млн кеше дигән сүз. Ел азагына бу күрсәткеч **61** процентка җитәргә мөмкин.
- Республикада **11651** спорт объекты бар.





РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

МАЗАРБАШЫ МАҖАРАЛАРЫ

Без бел(мә)гән тарих

Бер төркем журналистлар Мари Эл Республикасының татарлар яши торган Бәрәңге районы белән танышып йөрибез. Мазарбашы авылының үзәгендә балкып утырган таш мәчет янына килеп туктадык.

Ярымай

Кунакларны каршы алырга чыккан авыл аксакалы Рәис ага Салихов кулына, бик кадерләп, ярымай тоткан. Вакыт-вакыт карап та ала, сыйпап та куя ул аны. Күренеп тора: безгә җиткерәсе сүзләре нәкъ шушы ярымай турында кебек. Мөгаен, зур сер саклыйдыр ул. Шулай булып чыкты да. Рәис ага, эзләнә торгач, ике гасырлык ярымайны кулга төшергән. Хәзер, пыяла колба эченә урнаштырып, мәчетнең түренә экспонат итеп куярга йөри.

Архив материаллары буенча, Мазарбашы мәчете (ул тирә-якта бердәнбер таш мәчет була) Йомышлы Оры авылыннан (хәзер Татарстандагы Арча районы Түбән Оры авылы) сәүдәгәр һәм сәнәгать эшләре белән шөгыльләнүче Мөэмин Хуҗасәитов акчасына төзелә. Мондый зур төзелеш өчен бу торак пунктны сайлап алу очраклы гына булмаган. Мөэмин Хуҗасәитов җирле сәүдәгәр Мәмәтовлар белән тыгыз элемтәдә була, аларны туганлык җепләре бәйли. Рәис ага Салихов та – Мәмәтовлар нәселенең бер вәкиле. Димәк, күп еллар буена ярымайны эзләве дә юкка гына булмаган. Йөрәк кушуы буенча эшләгән ул аны.

–1935 елда мәчет манарасы киселгәннән соң, ярымай юкка чыга, – дип, хатирәләргә бирелде Рәис ага. – Бик гаҗәп күренеш була ул. Манара авып барганда, ярымай бер читкә атылып китә дә эзсез югала. Атылып киткәнен дә, кая төшкәнен дә күрәләр, әмма таба алмыйлар. Аны бөтен кеше эзли. Хәтта районнан милиция дә килә. Аннан авыл халкы: «Ярымайны Аллаһ үзенә алды», – дип инанып яши башлый.

Ә дөреслектә хәл болай була. Манара бик озын булганлыктан, ярымай ераккарак, Гаяз Асапов дигән кешенең бакчасына атылып төшә. Кеше-кара килеп җиткәнче, хуҗа кеше аны җәһәт кенә ала да яшереп куя. Кулга алулар шаукымының иң кызган чагы икәнен исәпкә алганда, бу эшне, һичшиксез, батырлыкка тиңләргә кирәктер.

– Мин ярымай турында кызыксына башлаганда, Гаяз абыйның улы исән иде әле, – дип дәвам итә сүзен Рәис ага. – Үзендә икәнлеген яшермәде. Бирермен, диде. Мәчеткә яңа манара куйдырганда тәкъдим итеп караган ул аны. Кемдер: «Яңасын ясаттык бит инде. Шунысын куябыз. Искесе кирәкми», – дип әйтеп ташлаган. Чыннан да, яңа манарага яңа ярымай куелды. Тик мин тукталып калмадым, яңадан барып сорадым. Вәгъдә иткән иде, әмма озак та үтми, бакыйлыкка китеп барды. Өлгерә алмадым. Балаларыннан белешеп карадым. Алар бу хакта берни белмиләр булып чыкты. Шулай да: «Печәнлектә булса гына инде. Сүткәндә, ныклап эзләрбез», – диделәр. Бу вакытта гаилә, нигезне алыштырып, башка урынга йорт-җир корып йөри иде. Тик анда да булмады. Инде биләмәләрендә бер гараж гына утырып калды. Берзаман Гаяз абыйның оныгы: «Рәис абый, мен әле тизрәк, ярымайны таптык бит», – дип шалтыратты. Шунда яшерелгән булган икән. Бу 2008 ел иде. Ә мәчет 1821 елда төзелә башлап, дүрт елдан соң ачыла. Димәк, ике гасырлык тарих калкып чыкты дигән сүз бит инде бу. Ярымайны ул вакытта бер рус кешесе ясап бирә, чөнки татарларга тимер эше белән шөгыльләнергә ярамаган. Революция алды елларында авылда өч мәхәллә була. Ә бу таш мәчет безнең якның дини үзәгенә әйләнә. Уку класслары, китапханәсе була. Килеп укыган шәкертләр өчен тулай торак та төзиләр. Мәдрәсәбез хәзер дә эшли.

«Якташлар» газетасы мөхәррире Фәнил Мусин белән авыл аксакалы Рәис ага Салихов – икесе дә данлыклы Мәмәтов нәселен дәвам итүчеләр.

Алашайка

Мазарбашыннан күп нәрсәләр ишетеп кайттык әле без. Бу авылның русча исеме – Алашайка. Анысы «алаша» сүзеннән алынган булып чыкты. Авылга 1539 елда нигез салынган. 1700 нче еллар тирәсендә ул бик нык үсеш ала. Татар халкының билгеле бер җитештерү, эшмәкәрлек үзәгенә әйләнә. Шул исәптән ат заводлары да була. «Вятка» токымлы атларны шушында үрчеткәннәр, дөньяга таратканнар. Гадәттә читкә алашаларны сатарга тырышканнар. Шуңа күрә авылга Алашайка исеме бирелгән дигән версия яши дә инде. Атлар белән генә дан тотмаган Мазарбашы. Монда кәгазь фабрикалары, комач, хәтта көпчәк заводы да була. Гафти Файзуллов дигән авылдашлары Петербургтан бәрәңге алып кайтып, беренче тапкыр шушында сата, үстерә башлый. Ат үрчеткән нәселләрнең берсенә Шиһабетдин Мәрҗани дә кайтып йөргән. Сабан туйларында катнашкан. Мәрҗани дип йөртелгән чишмә авылда хәзер дә саклана. Гыйлем иясе үзе шул чишмәнең суын бик яраткан. Үзе белән дә алып китә торган булган.

– Гел эш белән шөгыльләнгәнгә, элек бездәге байларны «кара байлар» дип йөрткәннәр, – ди Наил Бариев. – Күрше авылларда сәүдә белән эш итүче «ак байлар» яшәгән. Без бабаларыбызның «эш аты» булганнарына горурланабыз гына. Хәзер дә авыл халкының эшчән, тырыш булуы нәселдән килә, дип уйлыйбыз.

Чыннан да, Мазарбашында бүген кул көчен эшкә җигүчеләр бик күп. Ниләр белән генә шөгыльләнми алар. Терлек, кош-корт та асрыйлар, яшелчә, җиләк-җимеш үстерәләр, агач, тимер эшен дә ят итмиләр.

Авылда яшьләр дә кала. Сүз дә юк, заводлар корган бабайлар белән чагыштыра торган түгел, әмма заманасына күрә тормыш арбасыннан төшеп калырга да җыенмыйлар. Бабалары эшен дәвам иттереп, Фәдбир Хисмәтуллин кебек токымлы атлар үрчетүче эшмәкәрләре дә бар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

ЧИГҮ ЧИР БЕЛӘН БЕР

81 яшендә яшь кызлар кебек йөгереп йөри, дөнья җимертеп яши әле ул. Сарман районы Карашай-Саклау авылында яшәүче Рәсимә Билалова турында сүзем. Зарлана торганнардан түгел ул, көче-дәрте ташып тора. Карашайга сәфәргә барганда, оста чигүче янына кереп, хәлләрен белешеп чыктык.

Рәсимә апаның сөйләү осталыгына да, юмор хисенә дә, күпкырлы булуына да таң калып утырдык. Аның күңеле һәркем өчен ачык. Зал идәненнән түшәменә кадәр тезелгән чиккән картиналары, тәрәзә пәрдәләре, мендәрләр, төрле бизәк үрнәкләре – барысы да күз явын алырлык.

– Әнкәй дә, апа да тегүче иде. Бишенче сыйныфта укыганда мин дә чигә башладым. Бервакыт апам сатиннан итәк тегеп бирде. Ян-якларыннан йөртеп кенә үрнәк сызды да шуннан өйрәнеп калдым. Үзем чигә башладым, – дип сөйли Рәсимә апа. – Чигү чир белән бер ул. Йоклый алмыйм, иртәнге сәгать 2дә, 3тә торып, чигүгә утырам.

Рәсимә апа чигүле картиналарын сатмый, болай гына өләшә икән.

– Кешеләргә өләшкәне дә 40лап кына бар. Балаларның туган көннәренә, дус-ишләргә бирәм. Сатасым килми. Бетәр әле. Бүләккә бирсәм бирәм, сатканым юк, – ди Рәсимә Билалова.

Чигү остасы кул эшләрен пыялалы рамга урнаштырып, стенага элеп куйган.

– Җепләрен кешегә әйтеп кайтартам. Картиналарга рамнарны заказга ясатам. Менә боларның берсе – 700, кайсы 1000 сум тора. Бөтен акчам шуңа китә, – ди ул, кул эшләре белән таныштыра-таныштыра.

Тагын бер гаҗәпләндергән нәрсә: Рәсимә апа күзлексез чигә.

– Җепне саплаганда да күзлек кимим. Быел гына күздән ут күренә башлады. Шуңа сирәк кенә, кичкә таба гына күзлек киеп алам. Бизәкләрнең бөтенесен дә үзем төшерәм. Берәрсенең челтәрендә матур чәчәк күрсәм, шуны төшереп алмыйча тынычланмыйм, – ди чигүче.

Рәсимә Билалова язучылар турында тапшырулар карарга ярата, тел язмышы өчен борчыла.

– Язучылар турында тапшыруларны яратып карый идем, хәзер бик күрсәтмиләр. Өлкәннәргә ярашлырак татарча тапшырулар күбрәк булсын иде. Татар өчен тырышучы кешеләребез китеп барды. Ярый әле яшьләр арасында да андыйлар бар.

Рәсимә апа башта авылда 25 ел сыер савучы булып эшләгән. Тормыш иптәше үлгәннән соң, Чаллыга китеп, 11 ел кошчылык фабрикасында хезмәт куйган. Дүрт бала үстергән, берсен җирләгән.

– Балаларны урнаштырырга кирәк дип, авылдан киттем. Чаллыда ике бүлмәле фатир алгач, аны кече улыма калдырып, кире авылга кайттым, – ди әбекәй.

Авылга кайткач, Рәсимә Билалова килен булып төшкән йортын яңадан тергезә.

– 18 тулганчы димләп, шушы авылга кияүгә бирделәр. Баштарак авыр булды инде. Тик ирем белән тату яшәдек, Аллаһка шөкер. Авылга кайткач, тәрәзәләр куйдырдым, батареяларны яңарттым, әкрен генә ремонт ясадым. Веранданы эшләттем. Балалар да кирәк вакытта кайталар, булышалар, рәхмәт яусын. Тик аларның – үз тормышлары. Гаиләләре, балалары бар. Сыерлар күп асрыйлар, үзләренең дә мәшәкатьләре күп.

Рәсимә апаның бер куанычы чигү булса, икенчесе – җыр, гармун. Әле бик матур итеп шигырьләр дә яза ул.

– Үземә кирәктә уйныйм да, җырлыйм да. Җае чыккан саен шигырь язам. Тик тора белмим мин. Гармун алып, җыр чыгарам да, шулай кайчагында елап, кайчагында юанып та алам, – ди ул.

Шигырьләре арасында танылган җырчы Илсөя Бәдретдиновага атап язылганнары да бар. Баксаң, аларның иҗади дуслыгы күптәннән дәвам итә икән инде. Рәсимә апа өендә җырчының фотоларын, үзе бүләк иткән плакатларын да күрдек.

– Илсөя минем өйгә килеп йөрде. Без бит клубка йөрдек, үз төркемебез бар иде. Кайларга гына бармадык, урыннар алып кайта идек. Яңа елда, авылдашларны котлап, шигырь язып алып бара торган гадәтем бар иде. Илсөя беренче концертын куярга килгәч, ул вакытта клубта оештыручы булып эшләгән Гүзәл (Илсөя Бәдретдинованың хәзерге концерт директоры. – **Ред.**) әйтә: «Рәсимә апа, берәр шигырь чыгар инде», – ди. Матур гына шигырь яздым, сөйләдем. Илсөя янына кереп, кочаклашып фотоларга төштек. Дуслыгыбыз шулай башланды.

Менә шундый үз куллары белән гүзәллек тудыручы, күңел матурлыгын бар дөньяга таратучы кеше Рәсимә апа. Бу яктан ул күбебезгә үрнәк.

Ләйсән САФИНА

Авыл җаны

Вәт, агай, ә!

Бүгенге язмам гомере буе диярлек авылда яшәгән 86 яшьлек әби турында. (Кемерово белән Зәйдә генә эшләп кайткан берничә ел.)

Авылның иң өлкәннәре ничек, нинди уйлар белән яшәп ята соң? Әлбәттә, язмышлар төрле: бәхетле картлык, үкенечле, ялгызлык, чирләр белән сыналганы бар... Н. түти (керәшен карчыгы ул) беркайчан бернидән зарланмый. Бер генә сүзне еш кабатлый: «Бер ялгызыңа ямансу инде». Дүрт ел элек бабае (бабаем дип сөйли ул) үлеп китә, шуннан бирле озата бара аны ялгызлык. Дөрес, өч баласы бар, әллә ни ерак та яшәмиләр. Кайта калсалар, Чаллы белән Зәй арасында берәр сәгатьлек юл. Кайтулары гына сирәк... «Һәркемнең үз тормышы инде, җайлары юктыр», – дип акларга тырыша ул аларны. Кызның җәйдән бирле кайтканы юк («Күрсәм, танымам да инде»), телефоннан да сирәк шалтырата. Сәбәп бар икән: «Фатирына ремонт ясый» (!). Ике улының берсе көн дә хәл белешеп тора үзе, икенчесе «ялгыш та бер шалтыратмый». Менә шулай яклап, саклап үстерә ул аларны. Эш эшләтмәдем шул инде, ди. Үзе һәрвакыт хәрәкәттә булса да, эш булганда эшләп калыгыз, менә безгә хәзер эш бирмиләр, көн үтми, ди. Ишегалларын, капка төпләрен ялт иттереп көрәп куйган, яздан бакча эшләренә керешә. Бакча зур, казучы да, чәчүче дә, су сибүче дә үзе. («Балаларны көтеп ятсаң, көз җитәр...») Үстергән бер әйберен кешеләргә өләшә. Алучы булса, шуңа күңеле була.

Шикәр чире белән чирли үзе, йөрәктән дә учлап дару ашый («Чаллыда дару калдымы икән дип борчылам инде»). Эшли-эшли яртылаш бөгелгән ул: биле инде тураймый («Борыным белән җир сөреп йөрим шунда»).

Әле башына уй кергән. Йорт иренә язылган булган, аның вафатыннан соң балалар өчкә бүлеп йөргәннәр дә, һәрберсенә уникешәр мең сум түлисе булгач, ул эшне туктатканнар. Хәзер газ өчен яңа килешүләр булгач, мине нишләтерләр икән, дип пошына. Балаларыңа хәбәр иттеңме соң, дим. Юк икән. Үзләре дә белә бит инде алар аны, ди. Балаларын гомумән берни белән дә борчыйсы килми аның. Телефоннан да үзе шалтыратмый: әллә ярата-лар, әллә юк, җайлары булса, шалтыратырлар әле, ди. Балаларның исә туган нигездә әллә ни гамьнәре юк икәнлеге сизелеп тора. Тәрәзәләрдән ажгырып салкын керә, лапаслар яңартуны көтә...

Мин аны «Җомга көн кич белән»дәге Бибинурга охшатам бераз.

Авылда сиксәнне узганнар өчәү икән; тагын бер йөз яшьлек әбине кызы алып киткән. Өлкән яшьтәгеләр арасында күбесе әбиләр икән, бабайлар фани дөнья белән иртәрәк хушлаша.

Әбекәйнең бөтен теләге – кеше кулына калмау, үз аягында йөреп, җиңел үлем белән китү.

Өенең каршында гына медпункт тора («Гел тәрәзәдән карап торам – беркем керми; картлар йөри алмый, яшьләр чирләми, кирәкле бер дару юк»). Ковидлы җәйдә андагы фельдшерның ничек «оператив» эшләвен күреп киткән идем инде үзем дә: ул күршедән кереп җиткәнче, Зәйдән ашыгыч ярдәм килеп җитте. Соңыннан да вакытында укол кадарга керүче булмагач, миңа бөтен белемем, кыюлыгымны эшкә җигәргә туры килде. Әбекәй әле дә миңа «үлемнән алып калдың бит син» дип рәхмәтләрен укый.

Ул фельдшерлары йорт янәшәсендә генә кибет тә тота иде. Срогы чыккан товарлары күп була, дип еш зарлана иде кешеләр – кибет ябылган икән инде. Намус я бар, я юк инде ул – башкаларга мөнәсәбәт һәр эштә ачык күрсәтә аны.

Әбекәй үзенчәлекле сарказм белән сөйләшә. Мөгаен, тормыш шулай чарлагандыр. «Ирек мәйданы», «Ясминә»не алдыра, татарча тапшырулар, татарча сериаллар карый. Соңгысы – «Җиде юл чатында» «бик дан түгел» икән. Сайланып торырга булмагач, карый инде. Хәбәрләрне тыңлый. Кайвакыт: «Вәт, агай, ә!» – дип гаҗәпләнүен белдерә. Артист җырчыларны исемләп белә, «досье»лары белән.

Шулай да безнең намазлы әбиләрнең картлыклары бәхетлерәк кебек тоела миңа. Биш вакыт намаз, догалар, китаплар уку... Аллаһка якынлык ялгызлыкның авырлыгын азайтадыр кебек. Ә Н. түти, үзе әйткәнчә, бигрәк ямансулый шул.

P.S. Мин барында газ карауычы егет кереп чыкты әле. Дүрт күз белән көткән иде аны әбекәй, кичә үк чакырган булган. Газны арттырырга ярыймы, алай итсәң, ни була, болай итсәң, куркыныч түгелме – сораулары күп иде. Дорфа егетне ай күрде, кояш алды. Әллә никадәр соравы белән аптырап утырып калды әби.

Минем сорауларыма да бер генә җавап ишетелде җирле «царек»тан: «минем эшем түгел ул».

Яклаучысыз булуыңны белсә, азына шул мәнсезлек. Вәт, агай, ә!..

Лилия ФӘТТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Ябыгырга ярамый

Бөтен яктан бер фикерне кабатлыйлар: «Ябыгырга кирәк. Тән авырлыгы бөтен организмга зыян китерә».

Дөрес кебек ишетелә ул. Әйтик, синең авырлыгың йөз кило икән, син кая барсаң да, нәрсә эшләсәң дә, шул йөз килоны күтәреп йөрисең. Ә илле килолы кеше илле килосын йөртә. Чуешь ыразницу? Ул да – кеше, син дә – кеше. Ул – илле кило, син – йөз. Димәк, син тегеңә караганда күбрәк интегәсең, синең илле кило авырлыгың артык. Димәк, җилкәңә һәрвакыт бер капчык бодай күтәреп йөргән шикелле. Кемнең организмы тизрәк туза шулай булгач? Кемнең сәламәтлеге ныграк какшый? Әлбәттә, йөз килолы кешенеке. «Ничек кичекмәстән ябыгырга кирәк».

Бу фикер инде хәтсездән һәм бик зур басым белән кабатлана. Сиңа хәбәр итәргә, аңлатырга гына телиләр түгел, сиңа шул фикерне сеңдерергә, күңелеңә киртеп куярга, шул фикер белән сине бәйләп-тышаулап тотарга тырышалардыр кебек.

«Артык авырлык бөтен организмның эшчәнлегенә тискәре йогынты ясый, йөрәк-кан тамырларын, баш миен, аяк-кулларны, ашкайнату системасын, тын юлларын, бавырны, бөерне, үт куыгын зарарлый, шикәр чире, остеопороз, артроз, артрит, гипертония һ.б. авыруларга сәбәпче була». Әйтерсең, ябык кешедә бу чирләрнең берсе дә булмый инде...

Куркытып әйтелгән сүз дөреслек булып ишетелә. Ябыгырга кирәк! Бер генә артык грамм да калырга тиеш түгел.

Моның өчен бөтен шартлар да тудырылган. Әллә күпме спортзаллар эшли. Әллә күпме дарулар бар – рәхим итеп кенә өлгер. Диеталар. Китаплар. Кулланмалар. Хәтта ашый-ашый ябыга торган ысуллар да бар икән. Фәлән хәтле акчасын түгә-түгә, менә шундый ысуллар белән ябыга да кеше, акчасы беткәч, туктап кала. Һәм кабат авырлык җыя башлый. Гәүдәсе шул килеш кала, кесәсендәге акча авырлыгыннан гына котыла теге.

Ләкин авырлыкның артык икәнен кем белә? Бераүдә – йөз кило, икенчесендә – илле, ди. Әйе, беренчесе илле килога авыррак. Ә кемнең авырлыгы артыграк? Беренче кеше – ике метрлы, сөякләре эре, җилкәсе киң. Гулливер кадәр. Ә икенчесе кечкенә гәүдәле. Һәм ул – илле кило! Кайсының авырлыгы артык соң инде монда? Бәлки, икесенеке дә нәкъ үзләренә таман гынадыр?

Спорт белән шөгыльләнергә кирәк, диләр. Нинди спорт? Спорт ябыктырмый. Югары авырлыктагы боксчылар, көрәшчеләр бар. Сумоистлар бар 120–150 килолы. Рәхәтләнеп шпагатка утыралар, сальто ясыйлар. Сыгылмалылык та, житезлек тә, көч тә бар аларда. Авырмыйлар да. Димәк, үз авырлыклары шундый. 150 кило. Аларның организмы үзен шул халәттә әйбәт тоя.

Артык авырлык бик әйбәт түгелдер. Артык нәрсәнең барысы да зыянлы. Хәтта ул мөлкәт я акча булса да. Ләкин миңа ябыгу мәсьәләсендә төшенчәләрне аз гына бутыйлардыр сыман тоела. Симерү шикәр чиренә китерә, диләр, мәсәлән. Юк, алай түгел, нәкъ менә киресенчә: шикәр чире симерүгә китерә. Чир китерә симерүгә, ә киресенчә түгел. Һәрвакыт дип әйтеп булмый, күп очракта шулай. Кешенең ниндидер агъзасы, әйтик, йөрәге үз вазыйфаларын үти алмый, үз эшен вакытында башкарып чыга алмый, иртәрәгә калдыра. Ләкин икенче көнне дә йөкләмәсе түгел, ул көннең дә үз хәстәрләкләре бар. Йөрәк тырышып-тырышып эшли, еш-еш тибә, тик барыбер ерып чыга алмый. Тагын иртәгәгә калдыра. Шул рәвешле, моның калган эшләре май булып җыела, тын алырга да ирек бирми. Нәтиҗәдә ул хәлдән тая, аяктан егыла. Монда аның маен алып ташларга (ябыгырга) түгел, ә йөрәкне көндәлек мәшәкатьләрен үзе ерып чыгарлык хәлгә китерергә кирәк.

Организмның авырлыгы вакыт белән дә үзгәрә. Яшь чакта ул сөйгән егете янына чыккан кыз кебек җыйнак була. Аңа берни дә кирәкми: бар байлыгы үзе белән – бизәнгечләр, бүтән кирәк-яраклар салынган сумочкасын иңенә аса да канатланып оча гына. Олыгая төшкәч, кышларга дип шәһәрдәге килененә барган әби хәленә кала: төенчек өстенә төенчек җыела – алмаш кием дә кирәк, даруларын да тутыра, йөзләре ачылмасмы, дип тавык-казын да ала. Шулай итеп, картая-картая организмның йөге арта, ул калыная, киңәя, авырая башлый.

Ябыгуның иң ышанычлы һәм зарарсыз юлы берәү генә. Башта картаюдан котылырга кирәк, аннан – чирләрдән һәм иң соңыннан гына тегe яки бу урында җыелган майлардан. Хәер, соңгысы бик мөһим дә түгел бугай. Яшь һәм таза организм май җыеп ятмый бит инде, нәрсәгәдер кулланып, яндырып бетерә.

Ябыгырга тырышуны мин болай күз алдына китерәм. «Монысы сиңа кирәкми, монысы артык!» – дип, шәһәрдәге киленеңә җыенган кортканың төенчекләрен талап алган кебек. Алмаш киемнәрен, күчтәнәчләрен, даруларын йолкып алып кына аннан кыз ясап булмый бит инде. Һәм кыз булу аңа кирәкми дә. Алтмыш-җитмеш яшьтә кыз булу ул унҗидә әби булу сыман... Адәм кыяфәтендә сурәтләсәң, безнең организм да шулай төсмерләнә. Аның үз вакыты, үз хәстәрләкләре, үз авырлыгы.

ТУГРЫ САНДУГАЧ

Хушлашу

Татар җыр сәнгатенең тагын бер шәхесе хакында «иде» дип сөйләшергә генә калды... Узган атна ахырында Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһировның үлеме турында хәбәр алдык. Тагын бер моңлы сандугачны югалттык. Яман шеш авыруы җырчының мәңгелек йортка күчүенә сәбәп булды...

tatar-inform.ru

Артист – һәрвакыт сәфәрдә, юлда, гастрольдә. 25 декабрьдә Искәндәр Биктаһиров соңгы сәфәргә кузгалды. Үзеннән соң бай иҗади мирас калдырып...

Искәндәр Биктаһиров белән җыр сәнгатенең тагын бер мәшһүре Флюра Сөләймановаы озату мәрасимендә очрашкан идек. Күңеле тулы моң, күзләре мөлдерәмә яшь иде Искәндәр абыйның. Флюра апаның китүен дә авыр кичергән, күрәсең. «Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Габдулла Рәхимкулов, Флюра Сөләйманова. Мәшһүр дуртлекнең соңгысы иде Флюра апа», – дип сөйләгәндә, аның да тиздән китеп барасын берәү дә уйламагандыр.

Яшьләргә үрнәк, җыр сәнгатенә хезмәттә – алны-ялны белмәс, халык җәүһәрләре саналган җырларны үзенчәлекле итеп башкаручы. Җырчыны соңгы юлга озату мәрасименә җыелган халык әнә шундый итеп искә алды үзен.

Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин:

– Искәндәр абыйның активлыгы эстраданың бөтен яшь җырчыларына үрнәк булырга тиеш, – дип билгеләп үтте. – Аның халык җырларын башкаруының үзенә генә хас үзенчәлеге, үз юлы булды. Ялда булса да, ел саен Сабантуй графиклары белән кызыксынып торды. Мондый кешеләр, чыннан да, мәшһүр.

Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов – сәхнәдәш дусты белән сәнгать юлына бер вакытта баскан кеше.

– Иҗат юлымны аның белән бер чорда башладым. Без, яшь егетләр, халкыбызга хезмәт итәбез дип, җиң сызганып, татар җыр дөньясына килеп кердек. Искәндәр халык күңеленә матур, үзенчәлекле җырлары белән кереп калды. Югалып барган җырларны халыкка кайтарып, тиешле аһәңе белән җиткерә алды ул, – диде Айдар Фәйзрахманов.

Автор-башкаручы, продюсер Гүзәлия мәшһүр җырчыны эшенә тугры шәхес итеп тасвирлады.

– Элегрәк кем дә булса миңа: «Искәндәр Биктаһиров белән эшләячәксең», – дисә, ышанмас та идем. Әмма миңа аның белән эшләү, җырына клип төшерү мөмкинлеге тәтеде. Бу зур тәҗрибә булды. Шундый шәхес белән эшләү бәхет иде. Мин аңа шаккаттым. Ул чын мәгънәсендә үз эшенең фанаты иде, – диде ул «ВТ» хәбәрчесенә. – Үз эшенә шулкадәр тугры кешеләрне бик сирәк очратасың. Яше дә бар, авыруы да җитди. Әмма моңа да карамастан, Искәндәр абый гел позитив булды. Ә андагы энергия! Клип төшергәндә дә, аның өчен куркып тордым. Баскычларга да менде, биеде дә, карышмады. «Мин матур күренергә тиеш! Мин – артист кеше!» – дип кенә торды, бернәрсәне дә «әйдә, ярый»га калдырмады. Хәлем юк дигәнне ишетмәдем аннан. Чиста, пөхтә булды. Тугры сүзле, кыю кеше иде. Без бик рәхәт эшләдек. Үз тавышы белән иркен итеп җырлады ул! Монысына бөтенләй гаҗәпләндем. Андагы моң... Искәндәр абыйның иҗатка мөнәсәбәте – барыбызга да үрнәк. Хәзер «иде» дип кенә сөйләргә калды...

Казан шәһәре филармониясе директоры Наил Зыятдинов аның белән соңгы тапкыр сөйләшүен искә төшерде.

– «Кая чакыралар, шунда барам. Җыр – минем яшәү рәвеше», – дигән иде Искәндәр абый. Чынлап та, җыр белән яшәде, өендә дә, эшендә дә җырлады. Авыр туфрагың җиңел булсын, Искәндәр абый! – диде ул.

Җырчының улы Сәйдәш Биктаһиров аның белән рәхмәт әйтеп бәхилләште:

– Син безне чын кеше итеп үстердең. Мин синең белән балачактан ук гастрольләрдә йөрдем. Синең янәшәңдә үстем. Горурланам синең белән. Бәхил бул, әтием!

...Искәндәр Биктаһировны соңгы юлга озаткан көнне табигать тә тынычланды, җиргә ап-ак кубәләктәй карын җибәрде, кара җиргә пакь келәмен җәйде. Җырчының карaңгы гүре якты булсын, дигәндер. Аны «Курган» зиратында җирләделәр. Искәндәр Исмәгыйль улы Биктаһировның урыны оҗмахның түрендә булсын!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ТӨЗӘТЕП ТУЯЛМАДЫМ

tatarstan.ru

«Әләк» өчен – бүләк. Татарстанда инде өченче ел рәттән татар теленддәге элмә такталарда булган хаталарны ачыклау буенча бәйге уза. Күзгә күренерлек нәтиҗәсе дә бар – битараф булмаган кешеләр җибәргән 12 меңләп хатаның 9 меңе инде төзәтелгән. Кемнәр алар – урамнан барганда да тел өчен янып-көеп йөрүчеләр?

«Нигә рус телендә дөрес язалар да, татарчасында хата китә соң?»

Быелгы бәйгедә «Иң актив кулланучылар» номинациясендә беренче урынны алган Ирек Хәйруллинны әле дә әнә шул сорау борчый. Бу тынгысызлыкны тормыш иптәшенә дә «йоктырган» ул – Чаллыдан килгән Хәйруллиннар гаиләсе ике диплом белән кайтып китте.

– Хатыным Айгөл икенче урынны алды. Бу бәйгедә өченче мәртәбә катнашуым, ел саен бүләкләнәм. Ул хаталарны «Халык контроле» аша җибәрә башлаганда, бу бәйге турында белми дә идем, – ди Ирек. Шәһәрдә алар «әләкләгәч» төзәтелгән хаталарның саны 200дән арткан инде. – Әле дә карап йөрим, куанам. Шәһәрдә татар телендәге элмә такталарның артуы да сөендерә. Шәхси эшмәкәрләрнең дә җаваплылыгы артты, шәһәр хакимияте дә битараф түгел. Нәтиҗә бар, кыскасы.

«Киләсе елга җибәрергә хаталар калдымы соң әле?» – дип кызыксынабыз. Бар икән әле. «Игътибарлы булырга, иренмәскә генә кирәк», – ди җиңүче Хәйруллиннар.

Төзәтә-төзәтә...

Бәйгегә йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов та катнашты.

– Урамдагы мәгълүмат чараларында булган хаталарны төзәтү мәсьәләсе бәйге рәвешендә алып барыла. Соңгы өч ел эчендә генә дә без 10 меңнән артык гариза алдык, 9 мең хата төзәттек. Шактый эш башкарылды. Ләкин бу – киләчәктә дәвам итәләчәк эшнең кечкенә генә бер өлешедер. Бәйгене киләсе елда да дәвам итәргә исәбебез бар. Республикабыз зур, мәгълүмат бик күп. Мәгълүмат күп булгач, хаталар да күп. Аларны төзәтә-төзәтә, камиллеккә ирешергә язсын! – диде ул.

Элмә такталарда, игъланнарда, белдерүләрдә һәм башкаларда булган хаталарны «Халык контроле» аша кабул итеп, алар өчен җаваплы кешеләр төзәткәнче контрольдә тотарга кирәк. Бу эш өчен җаваплы Татарстандагы Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Сәрия Сабурскаяны битараф булмаучыларның күп булуы сөендерә генә.

– Хаталарны кабул итеп алдык та эше бетте түгел. Аларны төзәтү шактый вакытны ала. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты катнашучылардан килгән мөрәҗәгатьләрне карый, хата чыннан да бармы икәнен тикшерә. Булган очракта, аны төзәтү финанс чыгымнары да таләп итә бит әле, – дип сөйләде ул. – Быел бу бәйгене өченче мәртәбә уздырабыз. Ел да катнашучыларның күп булуы, республика халкының битараф булмавы бик сөендерә. Быелгы бәйгедә 33 район һәм 83 оешма катнашты. Яшермибез: җиңүчеләрне билгеләү бик кыен булды.

Эшнең фәнни ягы өчен Татарстан Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты җаваплы. Институт хезмәткәре Лилия Гыйниятуллина иң еш очрый торган хаталарны атады.

– Алдагы еллар белән чагыштырганда, быел хаталар табып җибәрүчеләрнең саны бераз гына кимрәк булса да, катнашучы районнар саны күп. Иң еш хаталардан сүзләрнең язылышына, сүз тәртибенә, грамматик формаларның кулланылышына, кыскартуларның дөрес кулланылмавына кагылышлыларын атарга була. Аларга җиңүчеләр елдан-ел күбрәк игътибар итә, – диде ул.

Фикер

Марат ӘХМӘТОВ:
– Мәгълүмати такталар – телебезнең көзгесе. Ул – милләттәшләребезнең, җаваплы кешеләрнең, урындагы җитәкчеләрнең телебезгә карата булган мөнәсәбәте.

Яңалыкларга килгәндә, быелгы конкурска беренче номинация өстәлгән. Хаталар эзләүдән тыш, быел мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү оешмаларының, Республикада җитештерелә торган продукциянең (товарларның), оешмаларның милли стильдәге бизәлеше бәяләнде, элеге конкурсны бик яхшы итеп оештырган районнар бүләкләнде. Әлеге мәсьәләгә битараф булмаган җитәкчеләр һәм үзәмшуллулар да читтә калмады.

Чаллымы, Яр Чаллымы?

Очрашу азагында тагын бер проблемалы мәсьәлә калкып чыкты. Иң күп хата тапкан Ирек Хәйруллин мондый әчтәлектәге үтенечен җиткерде:

– Шәһәргә Алабуга ягыннан кергәндә «Чаллы» дип язып куйганнар. Мин аны хата санап, «Яр Чаллы» дип төзәтүне сорадым. Мөрәҗәгатемне кабул итмәделәр. Моны 2005 елның 26 гыйнварында кабул ителгән 47 нче карар белән расладылар. Ул карар нигезендә, Чаллы муниципаль берәмлегенә татар телендә «Чаллы», рус телендә «Набережные Челны» дип атама бирелгән. Ә Юстиция министрлыгы карамагындагы рәсми документларда ул «Яр Чаллы муниципаль берәмлеге» дип аталган. Бу мәсьәләне ничек дә очына чыгарга кирәк иде...

Марат Әхмәтов бу сорауны белгечләр белән берлектә хәл итәргә вәгъдә бирде.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Халык сәламәтлеген саклау эшенә һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле фәнни эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең кардиология кафедрасы мөдире **Галявич** Альберт Сәрвәр улы **«Татарстан Республикасы алдынгы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Эшендә югары күрсәткечләргә ирешүе, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга өлеш кертүе өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе полиция патруль-пост хезмәтенең полк командиры, полиция полковнигы **Портнов** Александр Дмитриевич **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Гинсбург** Владимир Срульевич, Конфессияләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Рус Православие Чиркәвенең (Мәскәү Патриархаты) Казан Епархиясе Раифа Богородица ирләр монастыре» дини оешмасы игумены **Рожнов** Роман Алексеевич (Гавриил), Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы хезмәткәрләре: икътисад тармакларын финанслау бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Сәлахова** Лилия Исмәгыйль кызы, идарә аппаратының финанслау бүлеге әйдәүче консультанты **Чистякова** Оксана Сергеевна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесенең читтән торып уку факультеты башлыгы, полиция полковнигы **Красовский** Вячеслав Михайловичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы баш тикшерү идарәсенең оешкан җинаятьчел эшчәнлекне тикшерү буенча тикшерү часте икътисад өлкәсендә оешкан җинаятьчел эшчәнлекне һәм коррупциячел җинаятьләрне тикшерү бүлеге башлыгы, юстиция подполковнигы **Хәсәнов** Рамил Ринат улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы «Наз» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәсе социаль эш буенча белгече **Гарипова** Лилия Сирин кызына, Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге 6 номерлы пенсияләр билгеләү бүлеге баш белгече-эксперты **Гыйззәтова** Гөлсинә Гарифулла кызына **«Татарстан Республикасының атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәре Идел буе районының «Россия Герое Д.Р. Гыйлемханов исемендәге 42 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы **Зәетова** Гүзәлия Әхтәм кызына, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәренең Советлар Союзы Герое М.С. Фомин исемендәге 1 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең математика укытучысы **Сабирова** Гүзәл Равил кызына, Казан шәһәре Вахитов районының «Инглиз теле тирәнтен өйрәнелә торган 39 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы **Скокова** Елена Степановнага **«Татарстан Республикасының атказанган укытучысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Гел «бишле»гә

Апаем иртә китте дөньядан. 1991 елда, 53 яше дә тулмаган иде... Тарих фәннәре докторы, профессор Саттарова Флера Фәтхрахман кызы, гел «бишле» билгеләренә генә укыган тирән белемле гадел укытучы иде. Фәнни коммунизм... Студентларга шуны укытты... Табигате белән чиста күңелле, дәреслекне бар нәрсәдән дә өстен күргән, туган җанлы апаебыз мандолина, баянда уйный һәм гаҗәеп матур җырлый иде. Кулына баянын алса, үзенең яраткан җырын:

«Зәңгәр чәчәк ата торган
Гөлләр дә була икән.
Дөнья булгач, бик сагынган
Көннәр дә була икән...» –

дип җырлады. Пединститутта узган байтак чараларда чыгышлар ясады апаем. Пластинкалардан тыңлап, чит телдә башкарылган бик күп җырларны да белә иде.

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

Кышкы авыл

Илдар Мөхәммәтҗанов

Карлы-бәсле авыл. Малай-шалай
Боз өстендә алка тибәләр.
Язылмаган дәфтәр битләредәй,
Агарынып ята түбәләр.
Морҗалардан чыккан ялкау төтен
Чорнала да елгыр буранга,
Мунчаларның төмле исен тояп,
Ял итәргә кача урманга.
Яшел җәйне төргәк-төргәк итеп
Әлеп куйды икән кем анда? –
Кычыткannар, кипкән мәтрүшкәләр
Калтырана салкын чоланда.
Язны чакырамы тәрәзәләр –
Чәчәк аткан бозлы пыяла.
Кабарынып, саклык белән генә
Томышык сузган бер кош ояда.
Ул күрсәгез иде сабыйларның
Ак келәмнән атлап барышын!
Чана җиккән җитез аргамаклар
Карга тими чаба узышып.

...Карап торсаң, бер әкият сыман,
Кызык та соң авыл тормышы!

Вазыйх ФАТЫЙХОВ

КУЛЛАРЫННАН ГӨЛ ТАМА

Кыш аена аяк баскан көннәрнең берсендә Кукмара шәһәре Үзәк китапханәсендә Кәркәүч авылында гомер кичерүче Мөнип Фатыховның үзе ясаган картиналарыннан күргәзмә ачу тантанасы булып узды. Бу кичәгә Мөнипнең туганнары, дуслары, якташлары һәм Казан шәһәреннән Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, рәссам, педагог Мөдәрис Минһаҗев, җырчы, профессор, Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев, композитор, автор башкаручы Илфат Дәүләтшин килгән иде.

Мөнип күккә ашкан биек таулары, чәчәкле болыннары, авылга авам-авам дип торган катнаш урманы, авылны икегә бүлеп агып ятучы Шөн елгасы булган Кәркәүчтә туып-үсә. Ә инде челтерәп агып ятучы Потап чишмәсе, тау чишмәсе үзләре генә ни тора!

Шушындый матур табигатьтә тәгәрәп үскән бала ничек рәссам булмасын инде?! Без дә шушы матур табигатьтә кайнашып үстек, ләкин бездән рәссам чыкмады шул. Бу – Мөнипкә туганнан бирелгән сәләттер, мөгаен.

Мөнип 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, ике ел армиядә хезмәт итә. Армия хезмәтеннән соң Казанда рәссам-бизәүчеләр әзерли торган уку йортын тәмамлый. Аннан соң колхозга рәссам-бизәүче булып эшкә урнаша. Совет заманының болганчык чорында аны эшеннән кыскарталар. Кирәгең чыкса, чакырырбыз, диләр. Шул чорда үзе өчен, якыннарына бүләк итәр өчен, төрле төсле буяулар белән табигатьнең матурлыгын, әти-әнисен, балаларын картинага төшерә башлый.

Алга таба аны үз авылы мәктәбенә завхоз итеп эшкә алалар. Шушы эшендә 10 ел эшләү дәверендә ул читтән торып Чаллы педагогика институтының графика-сәнгать бүлеген тәмамлый. Ә мәктәптә рәсем укытучысы да булып эшләп ала.

Бер елны Саба районы Миңгәр авылында рәссамнар чара үткәрүгә җыела. Ул авылда яшәүче кодагыем:

– Мөнип, син бик оста итеп рәсем ясыйсың. Картиналарың да бик күп, әйдә монда кил әле, үзеңне күрсәтеп кара, – диде.

Бу чарада рәссам Мөдәрис Минһаҗев та була. Ул минем кулга рәсем ясауда кулланыла торган барлык әйберләрне тоттырды да:

– Миңгәрнең матур табигатен яса әле, – диде. Һәм мин ясадым.

Шушында катнашкан 40 кеше ясаган картина арасыннан 20се сайлап алына. Алар арасында Мөнипнең эше дә була. «Иии сөендем инде», – дип искә ала Мөнип ул көннәрне.

Менә шул көннән Мөнипнең Казан рәссамнары белән арасы өзелми. Аны алар үзләре үткәргән күргәзмәләргә дә дәшәләр.

Менә ул үзе дә, тәвәккәлләп, эшләренең күргәзмәсен оештырган.

Китапханә диварларын Мөнип ясаган картиналар бизи. Искиткеч картиналар, караган саен карыйсы килеп тора!

«Картиналарыңны сатып акча эшләп буламы соң?» – дигән сорауны да бирми калмадым.

– Күбесен бүләк итәм. Акчаны мин башка юл белән дә эшли алам, – дигән җавап ишеттем мин аннан.

Кукмара китапханәләр системасы директоры Резидә Хәкимулловна күргәзмәдәге рәсемнәргә уңай бәя бирде. «Мондый күргәзмәләр китапханәбездә быел өченчесе инде һәм соңгысы да булмас», – дигән фикер әйтте. Рәссам – матурлыкка мөкиббән кеше. Мөнипнең үзенең йөзеннән дә нур бөркелә. Күргәзмәсе исә һич оныта алмаслык булып хәтердә калыр.

Рафилә ФӘТТАХОВА. Кукмара

«ПОРТ-АРТУР» ДИГӘН КАЛАГА...

Узган гасырның җитмешенче елларында Яңа Рәҗәптә (хәзер Чәчәкле) «Порт-Артур»ны көйләп йөргәннәрен хәтерлим. Күршедә генә яшәгән Рәфыйк абый Хафизов та (урыны оҗмахта булсын) машина йөрткәндә яратып җырлый иде. Ни өчен авылдашлары моңсу бу җырны үз иткән?

Беркөнне миннән олырак булган Илгизәр Хәйдаровтан сораштырып торган идем. Шактый кызыклы нәрсәләр турында сөйләде ул:

– 1904 елның 9 февралендә кабынып киткән рус-япон сугышында безнең авылдан да берничә кеше катнашкан. Мисал өчен, Рәфыйк абыйның әтисе Хафиз бабай, минем бабам Хәйдар Мөхәммәтҗанов шул сугышта булып кайткан. Дәреслеккә туры килсә, авылдан ким дигәндә унлап кеше барган булырга тиеш. Бабай да шул санны әйтә торган иде. Бу сугыш турында ул бик ачылып китеп сөйләргә яратмады. Кәефе булганда берничә эпизодны хәтерендә яңартып ала торган иде. Кызыксынып сорый башласам, үзәгенә үткәнгәдер инде, сүзен гел икенче темага борып җибәрдә. Әйе, сугыш уен түгел. Кемнең инде күрә торып ут эченә барып керәсе килсен? Шөкер, ашый торган ризыклары көткәнгәдер инде, Хафиз бабай белән Хәйдар бабам япон сугышыннан, яралансалар да, үз аякларыннан белән, исән килеш кайтканнар. Бабайның маңгае тегелгән иде, япон ядрәсе керде, өшетмичә-нитмичә генә акыртып тартып алдылар, дип сөйләде. Сугышта кыю, бик гаярь булган ул. Юкка гына IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләмәгәннәрдер шул! Солдат бүләген кульяулыкка төреп, Коръән китабы белән бер тирадәрәк саклады. Шуны ялтырап торган дәрәҗәгә җиткәнчегә кадәр чистартып куя иде.

Хәйдар бабайның «Каенлык» артында имана җире булган. Шуны эшкәртеп бодай үстергән. Шунысы гаҗәп: бабайга кайдан килгән бу җир? Рус-япон сугышында катнашкан өчен бирмәгәннәрме икән? Ул елларда бит авыл крестьяннары җирле булу турында хыялланa да алмаган. Шул кырдан җыеп алган бодайны эшкәртү өчен бабай ызандаш Ульяновск өлкәсенең Колгреевка авылындагы танышларыннан, ат арбасына салып, кечерәк бер сортировка алып кайта торган булган. Моңа авылдагы күп кеше көнләшкән, бабайга кырын караучылар саны арткан. Аның руслар арасындагы танышлары белән даими аралашуын кайбер куштаннар бик ошатып бетермәгән. Җитешле, мул тормышта яшәгәч, хәтта кулак дип йөртүчеләр дә булган әле.

Илдә колхозлар төзү чоры башлангач, авылда яшәүчеләрне көчләп хуҗалыкларга кертү эше күп җәелдерелә. Карышып маташучылар белән сөйләшеп тә тормыйлар, хәлләрәк саналган кешеләрнең бөтен мал-мөлкәтен тартып алалар, үзләрен исә хөкемгә тарталар. Бабай белән дә озак сөйләшеп тормаганнар, йорт-җирен таратып, үзен Спас төрмәсенә алып киткәннәр. Нәүбәһәр әби картын кызганып бик кайгырган, йөрәге түзмәгәч, капчыгына ипи белән бәрәңге салып, Спаска чыгып киткән. Бер надзиратель белән сөйләшеп, шуны кемдер аркылы Хәйдарына тапшырып кайта алган. Нәүбәһәр әби, намазга баскан саен, иренә саулык теләп, догалар кыла, Ходайга ялварып, ирен азат итүен сорый. Әмма картын алай тиз генә төрмәдән чыгармыйлар шул. Инде нишләргә? Башка чара калмагач, Хәйдар бабайның русчаны аз-маз белгән Садыйк атлы улы, җыеныр, Мәскәүгә Сталин янына дип чыгып китә. Ничек үздыргаңнар аны Кремльгә – монысы билгесез. Үз кулы белән язган хатын кылтырый-кылтырый илбашчыга укып күрсәткән, безнең әти рус-япон сугышыннан Георгий тәресе тагып кайтты, дип аңлатып биргән. Шунысына ис китәрлек: авыл малаен Сталин кызганган булса кирәк, озакламый Хәйдарны Спас төрмәсеннән азат итәләр. Аны әле авылга кадәр ат белән кайтарып та куйганнар. Авыл куштаннары, ялагайлар бу хәлгә нык көенгән, хәтта әле бабайдан бераз шүрләп тә йөргәннәр.

Минем бабай алтын куллы кеше иде, нәрсәгә тотынса, шуны булдырды. Төрмәдән кайткач, колхозга водовоз булып эшкә урнашкан ул. Ат җигеп, җәй кырда эшләгән техникага төрле кирәк-яракны китереп торган, башка йомышларны үтәгән. Бабай вакытны беркайчан бушка уздырмады. Элек бит урманнан агач кисәргә ярамады, тотсалар, эшне гел зурга җибәргәннәр. Ул киселәгән имән төбен тамыры белән казып кайта торган иде. Шуны иренмичә кул пычкысы белән вакларп тураны һәм кыш буе ягып чыгарлык утын әзерләде. Бабай әле тагын үзлегеннән йорт хайваннарын дәвалярга өйрәнгән. Бик күп кешеләрнең терлеген үлемнән алып калды. Үзен әле авылларга да чакыралар иде.

Берсендә күршедәге Ульян өлкәсенең Сартоновка авылына мине дә ияртеп барды. Авыл башыннан чыгуга, бабай кесәсеннән кульяулыкка төрелгән Георгий тәресен күкрәгенә алып такты. Ике рәтле рус авылына кергәндә үк икебезне маржа әбиләре сырып алды. Ул да түгел, «Эх, наш солдат идет!» – дип бабайның аркасыннан чәбәкләп, нидер турында сораштыра башладылар. Әмма бабайның алар белән озаклап сөйләшеп торырга вакыты булмады. Без авылның аргы башына төшеп киттек. Берәүләрнең тәкәсен печеп чыкты, икенчеләренең сыерына очерергә дип кәчтүм кесәсеннән ниндидер дару алып бирде бабай. Әлбәттә инде, эшләрне тәмамлагач, аңа акча биргәннәрен һәм өйгә чакырып сыйлаганнарын хәтерлим.

Кайтканда, бабайның күңеле күтәренке иде. Түбәтәен басыбрак киеп «Порт-Артур»ны көйләп алды: «...дигән калага японнар туп аталар, их-х-х...» Авылга кергәндә, Георгий тәресен яңадан кульяулыкка төреп, кесәсенә салды. Кешегә күрсәтергә теләмәгәнгә шулай иткәндер әле ул. Мөселман кешесенә мондый нәрсәне тагып йөрергә ярамаганлыкны да белде ул. Әмма нишләтәсең, яу кырында патша өчен кан түгеп алган бит ул аны. Кызганыч, хәзер инде авылда «Порт-Артур» җырын җырлаучылар бетте. И, бу гомерләр, кемне искә ала башласаң, шул юк...

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

Редакциядән: Редакциябезнең якын дусты, Спас районында нәшер ителүче «Яңа тормыш» газетасы мөхәррире Тәлгать Җамалетдинов шушы араларда бакыйлыкка күчте. Аңа 60 кына яшь иде әле. Мәкаләсен: «И, бу гомерләр, кемне искә ала башласаң, шул юк...» – дип тәмамлавы сискәндерә дә, уйландыра да. Эш өстәле янында җан бирә ул. Урыны оҗмах түрләрендә булсын!

Яшьлек хатирәләре

Уйларым балачакка йөгерә

Уйларым әледән-әле балачакка йөгерә, бик сагынам үсмер чагымны.

Без мәктәптә укыганда һәр җомга көнне дәрестән соң ялгыз әби-бабайларга барып, аларга азмы-күпме ярдәм итеп кайта идек. Шундый әбиләрнең берсе Зәкия исемле иде. Ире һәм улы сугышта вафат булган, әби ялгыз гына гомер итә. Әниебез коймак, тәбикмәк пешереп, Зәкия әбигә күчтәнәч итеп җибәрә. Ярылган утыннарны өйгә мич арасына кертеп, иданнарын юып, эчәрәнә чишмәдән су алып кайтып куя идек. Әби безне өстәл янына чакыра, өч-дүрт балага чәй әзерли, өйдәгеләр биреп җибәргән сый-нигъмәт белән сыйлый, үзе дә сыйлана. Шунда ук хатирәләрен дә яңартып ала, без тын да алмый тыңлыйбыз.

Суга йөри торган чишмәбез Фәйзуш (Фәйзулла) чишмәсе дип атала иде. Чишмә тавын исә Фәйзуш тавы дип йөрттеләр. Кыш көннәрендә чишмәгә суга килгәч, көянтә-чиләкләребезне чишмә буенда калдырып, таудан чана шуа идек. Өскә кигән киемнәребез бозланып каткач кына, арып-талып өйгә кайтып егылабыз, су алып кайтырга хәл калмаган була иде.

Без яшь вакытта бәрәңгене хәзерге кебек август аенда түгел, сентябрь башында ала идек. Шау-гөр килеп, бөтен гаилә белән өч-дүрт көн казыйбыз. Өлкәнрәкләр бәрәңгене көрәк белән казый, балалар җыя, кечкенәрәкләр капчыкның авызын тотып тора. Һәр бала ничә яшьтә булуына карамастан, үзе булдыра алган эшне башкара. Әти-әни безгә, пычраныл йөрмә, буталма әле аяк арасында, дип беркайчан да әйтмәде. Киресенчә, мактап, баштан сыйпап, үсендереп тордылар. Без менә шулай эшкә өйрәнеп үстек.

Мәктәптә укыганда атнага бер тапкыр бозаулар фермасына бару да гадәткә кергән иде. Үзебез белән акбур, күмер алабыз, болар – бозауларга витамин. Бозаулар исә безне таныл, мөгрәшеп каршы ала. Менә шулай яшьтән үк хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән әти-әнигә, укытучыларыбызга гомер буе рәхмәтле без.

Җәүһәрия ШӘРИПОВА. Азнакай

Әбием кебек була алмадым

Мин дөньяга аваз салганда әбиемә 54 яшь булган. Мин үземне белә-белгәннән бирле әби янәшәсендә булдым. Хәзер дә аның күз карашын, битендәге һәрбер җыерчыгын, миңен, хәрәкәтләрен хәтерлим. Ул минем өчен дөньядагы иң гүзәл кеше булып хәтердә саклана.

Әбинең биш баласы, егерме оныгы бар иде. Аның күңел җылысы барыбызга да җитте. Әбиебезнең тектән күлмәкләренең, бәйләгән оекбашларының җылысын хәзер дә тәнемдә тоям сыман. Әби бик күпне күргән, сабыр, акыллы, гадел, ихлас күңелле иде.

Беркөнне урамнан нәрсәгәдер үпкәләп кердем дә әбиемә сөйләдем. Ул тыңлап торды да: «Ярар, алай сине кассалар, моннан ары урамга чыкмассың, өйдә генә утырырсың, берәү дә бер сүз дә әйтмәс», – диде. Аның шулай дип әйтүе гомерлек сабак булды, үпкәләмәскә, урамнан сүз ияртеп кайтмаска өйрәндем. Әбиемнең тәрбия-сабаклары үземнең гаиләмдә дә бик ярап куйды. Балаларымны да: «Әбиегез менә шулай дип әйтә иде», – дип үстердем. Шушы көнгә кадәр шатлыкта да, кайгыда да иң әүвәл әбиемне исемә төшерәп, ул бу очракта нишләр иде икән, дип аның белән «серләшәм».

Әбидән гел үрнәк алып яшәдем, ләкин ничек кенә тырышсам да, аның кебек эшкә дә, сүзгә дә оста була алмадым. Биргән тәрбиясе тормышымны мәгънәле, мул итте.

Римма ХАФИЗОВА. Алабуга

Чапшарым – чишмәләр иле

Безнең авылны борынгыдан ук «Кырык бер чишмәле Чапшар» дип йөрткәннәр. Авырган кешеләрне еракларадан алып килеп, безнең авылның чишмә суларын эчертеп дәвалый торган булганнар. Чапшарыбыздан урман да ерак түгел. Менә шул урман эченә азрак кергәч, Кәлти чишмәсе бар. Бу чишмәне тирә-якта белмәгән кеше юктыр.

Берничә ел элек авылдашларыбыз, җыелышып, Кәлти чишмәсен чистарттылар, өстенә бик матур итеп корылма да ясап куйдылар. Әле күптән түгел игелек иясе Мансур Әхтәмов инеш буендагы тагын бер чишмәне карап, матурлады. Бу чишмә берәз гына коега да охшап калды. Аның тирә-ягына Мансур кордаш талдан читән дә үреп куйды.

Без үскәндә, өйдән ерак түгел Касыйм бабай чишмәсе дә бар иде. Ул – авылда беренче совет мәктәбен оештырган кеше, Ленин ордены кавалеры. Озак еллар Чапшар мәктәбен җитәкләгән. Чишмәне тәртиптә тотып, изге гамәлләр кылып, Касыйм бабай исемен тарихта калдырды.

Классташым Наил Мәрдановның бакча башында да чишмә бар. Күптәнге, билгеле чишмә. Авылыбызның иске клубы артында да бик шәп ага торган чишмә бар әле. Без гомер буе шуннан су ташыдык. Аның янында элеккеге елларда Даһия апайлар белән Гарәфи абый Фәләхов гаиләләре яшәде. Мин әйтәм, бәхетле булганнар, җырлап торган чишмә янында гына яшә әле син!

Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«ТАИФ» төркеме коллективы, хатыны **Рауза Мәгъсум кызы**ның кинәт вафат булуы сәбәпле, «Татнефтехиминвест-холдинг» акционер җәмгыяте генераль директоры Рафинат Самат улы Яруллинның авыр кайгысын уртаклаша. Рауза Мәгъсум кызы изге күңелле, мәрхәмәтле хатын, сөекле хатын һәм ана буларак хәтеребездә уелып калачак.
Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең традицион уен кораллары белән таныштыра. Аның чираттагысын парапланга багышлыйбыз. Параппан – чуаш халкының традицион һәм иң популяр уен коралы. Бүген без аның мисалында чуашларның милли уен коралларының үзенчәлекләре, үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшербез.

Милли аккорд

МАХСУС ПРОЕКТ

ЧУАШ АНСАМБЛЕ ҖИТӘКЧЕСЕ:

«ХӘЗЕР НИ ДӘ БУЛСА КЫЛМАСАК, СОҢ БУЛЫРГА МӨМКИН»

Параппан һәм, гомумән, чуаш халкының тридицион уен кораллары кай ягы белән үзенчәлекле? Яшь буын алар белән кызыксынамы? Кызыксынсын өчен нишләргә?

Әлеге сорауларны без Тәтеш районының «Шуҫăм» халык ансамбле җитәкчесе Алена СТАРОСТИНАга бирдек.

:: Алена Геннадьевна, сез җитәкли торган ансамбль турында сөйләгезче. Җыр-биюләрдән тыш, чыгышларыгызны халык уен кораллары да бизи дип беләм.

– Безнең ансамбль 2014 елдан бирле эшли. Ул вакытта нибары биш кешедән җыелган иде ул, алары да – пенсия яшендәге апа-абыйлар. Хәзерге вакытта ансамблебезгә 11 кеше йөри. Коллективка яшьләр дә килә – шуңа сөенәбез. Районда гына түгел, республика күләмендә уздырыла торган чараларны калдырмаска тырышабыз, чуаш авылларына гастрольләр белән дә чыгабыз әле.

Ансамбль репертуарында халык җырлары күп. Ә чуаш халык җырларының яңгырашын халык уен коралларыннан башка күз алдына китереп булмый. Бигрәк тә параппаннан башка.

:: Татарстанда параппан ясаучы осталар бармы?

– Кызганыч, безгә әлеге инструментны Чувашиядән алып кайтырга туры килә. Беренче параппанны 2006 елда Чабаксар шәһәреннән алып кайткан идек. Ул шактый искерде, таушалды. Әле менә бер ай тирәсе элек кенә өр-яңа параппанлы булдык. Аны безгә Чувашиядә яшәүче алтын куллы оста Николай Фомиряков ясап бирде.

:: Финанс мәсьәләсендә ярдәм итәләрме?

– Финанс мәсьәләсендә дә, башка яктан да район һәм республика ташламый. Зарланырга сәбәп юк, диясем килә. Әле менә күптән түгел генә зур эш башкардык – яңа костюмнар тектердек. Анысы да мөһим бит.

:: Алена Геннадьевна, чуаш халык уен коралларының нинди үзенчәлекләре бар?

– Чуаш халык уен коралларына милли код салынган. Алар – безнең халыкның күпгасырлык аһәңе. Бездә дүрт төркемгә карый торган уен кораллары бар: кыллы, тынлы, мембраналы, үзяңгыравыклы. Элек-электән аларның һәркайсы нинди дә булса функция башкарган. Музыкаль-эстетик функциядән тыш, алар төрле йола-обрядлар вакытында файдаланылган. Хәтта кайбер очракларда сигнал функциясен башкарганнар. Параппан – чуаш халык уен кораллары арасында иң популяры. Электән үк аннан башка бер генә бәйрәм, күңел ачу чарасы да узмаган.

:: Борынгы уен коралларының ансамбльнең аерылгысыз өлеше булуы сезнең өчен ни дәрәҗәдә мөһим?

– Бу, беренче чиратта, киләчәк өчен кирәк. Халык музыкасы һәм халык уен кораллары балаларны үз милләтенең гореф-гадәтләрен һәм мәдәниятен яхшырак аңларга ярдәм итә, башка халыкларның мәдәнияте белән кызыксынуга этәрә.

:: Халык уен кораллары онытылмасын өчен нәрсә эшләргә кирәк? Аның язмышы кем кулында?

– Бүген барысы да безнең буыннан тора. Без хәзер ул уен коралларын саклап кына калмыйча, аларны балалар өчен кызыклы формада тәкъдим итә белергә тиеш. Әгәр хәзер ни дә булса кылмасак, кабат инде соң булырга мөмкин…

КАН ТАРТУЫ

Ни өчендер параппанда һичшиксез ир кеше уйнарга тиештер кебек тоелса да, Маргарита Адайкина белән танышу бу фикеремнән кире кайтарды. Ун елга якын «Шуҫăм» халык ансамбленә йөри, музыка дәресләре укыта, Тәтеш районының ветераннар хорын җитәкли ул. Безгә исә параппанда уйнауның үзенчәлекләре турында сөйләде.

Параппан белән бербөтен булырга кирәк. Маргарита Адайкина сүзен шуннан башлады.

– Әлеге инструментта уйнауның төп сере – ритмны тоемлый белү. Бөтен булган авырлыгы да шулдыр, мөгаен. Инструмент белән бербөтен булырга кирәк. Һәм, әлбәттә, халык көйләренең ритмын яхшы белергә. Параппан ул көйләргә ямь, үзгә бер рух өсти. Анда уйнауның җаваплылыгы да зур, – диде ул.

Маргарита ханым уйный торган параппан тулысынча табигый материаллардан гына ясалган.

– Корпусы – каен агачыннан, мембранасы сыер тиресеннән ясалган. Хәзерге осталар фанер да файдалана. Нәкъ менә табигый материаллар параппанның яңгырашын үзенчәлекле итә дә инде, – ди музыкант.

Чуаш халык музыкасына булган мәхәббәт канына сеңгән аның. Нәселләрендә берүзе генә түгел – кайчандыр мәрхүм бабасы параппан ясый торган булган.

– Әлеге уен коралында профессиональ дәрәҗәдә уйный беләм, дип әйтә алмыйм. Белгечлегем буенча музыкант булсам да, профессиональ дәрәҗәдә фортепианоны үзләштердем мин. Ләкин, җан тартмаса, кан тарта, дигән кебек, халык уен коралларына битараф кала алмадым, – ди Маргарита ханым.

Аның да параппанның һәм, гомумән, халык уен коралларының киләчәге турында фикерен белештек. Булганны кадерләргә, читтән ярдәм көтеп ятмаска дигән фикердә ул.

«Параппанда уйнауның бер авырлыгы да юк», – ди Маргарита Адайкина.

Бар нәрсә дә кабатлана. Халык уен кораллары да тормышыбызга кире кайтачак. Алай гына да түгел, халкыбыз энҗе бөртекләре булган җырлар да, милли киемнәр дә киләчәк буын өчен бик зур мирас булачак. Ләкин ул мирасның киләчәге бездән тора һәм бик гади генә гамәлләргә барып тоташа. Балаларга аның турында сөйләргә, аны күрсәтергә һәм үзләрен дә мөмкин кадәр җәлеп итәргә кирәк.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Геннадий МАКАРОВ, сәнгать белеме кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт консерваториясе доценты

Идел-Кама төбәгендә яшәгән күпчелек этник төркемнәрнең борынгы мәдәниятендә бәрмә музыка кораллары киң кулланылган.

Алар кадими заманда формалашкан, әмма XX йөз башында кулланыштан төшеп калган һәм Европадан кергән уен кораллары белән алмаштырылган. Ике яклы барабан куллану чуаш һәм мари халкында гына сакланып калган.

Шул ук вакытта Яңа заманга кадәр яшәгән барлык халыкларда, шул исәптән татарларда бәрмә уен кораллары булган. Бу хакта төрле чыганаклардагы мәгълүматлар шактый күп булса да, алар әлегә кадәр фәнни яссылыкта аз өйрәнелгән. Татарларда кулланылган бәрмә кораллар турындагы мәгълүматларны фольклор әсәрләрдә табарга мөмкин.



Ике яклы барабаннарны кулланмау һәм фәнни яктан өйрәнмәүнең сәбәбе, күрәсең, әлеге традицияләрнең музыкаль даирәдә сакланмавына бәйледер.

Бу күренеш әлеге уен кораллары бөтенләй булмаган дигән ялгыш фикер барлыкка китергән. Әмма сакланган тарихи материаллар ясалма рәвештә булдырылган стереотипны үзгәртергә мөмкинлек бирә. XIX йөздә чыккан сүзлекләрдә татарларның төрле этник төркемнәренә хас лексикалары чагыла. Анда еш «барабан» дигән төшенчә очрый. Ул төрле үлчәмдә, конструкциядә һәм төрле атамаларга ия булган. Мәсәлән, А.Троянский төзегән татарча-русча сүзлектә «барабан», «барабанщик» төшенчәләрен нокърә, нокърәче дип тәрҗемә иткән [Словарь татарского языка… Александра Троянского. – Т. 1. – Казань, 1833. – 629 с.]. Алар хәрби лексикага карый. Патша хезмәтендәге йомышлы татарлардан формалашкан хәрби бүлекләр тормышына бәйле булган. «Думбрый» төшенчәсен А.Троянский русчага бубен дип биргән.

Керәшеннәрдәге бәрмә уен кораллары турында мәгълүмат этнографик экспедицияләрдә тупланган. Мәсәлән, думбрый, думбра исемле бәрмә уен коралы турында. Мамадыш районы Ташлыяр авылында бәйрәмнәрдә барабан кагып биегәннәре турында хәтерлиләр. Соңгы оста барабанчы Лыя авылыннан Бәчә карт була. Аны Комазанбаш, Дүсмәт авылларына туйларга чакырып уйнатканнар. Үзенчәлек шунда: барабанны мондагы халык думбра, думбрый, дөмбер дип йөртә. Ташлыяр авылында яшәүче Данилова Пелагея Петровна (1928 елда туган) сөйләве буенча, Бәчә карт әле 1945 елдан соң да берничә ел бәйрәмнәрдә думбрасын кагып биеткән. Тасвирлаулар буенча, думбра (думбрый) исемле бу мембрафонны сул култык астында тотканнар. Гармунга кушылып, «Чабата», «Камарски» һәм башка бию көйләре уйнаганнар. Тавышны ике тукмак белән сугып чыгарганнар. Коралның размерларын «чиләк чаклы» дип күрсәттеләр. Думбрый – кысасы уртасы уелып алынган агач төбеннән ясалган, як-ягына махсус эшкәртелгән эт тиресе баулар белән тарттырып куелган. Моннан күренгәнчә, бу ике яклы барабан Идел-Кама буе халыкларының борынгы традицион барабаннары мариларның тюмыр, тюмбыры, чуашларның параппаннары белән бер типта булган. Шушындый ук барабанда/думбрада аю биетүче мишәрләр дә уйнаган.

Ике яклы барабанны тубал исеме белән йөртү күренеше дә бар. Әмма күпчелек вакытта тубал дип кысалары калын кабыктан эшләнгән, язгы чәчү вакытында орлык алып чәчәр өчен, аны җилкә аша элеп йөри торган савыт төре турында әйтәләр. Тышкы күренеше буенча тубал борынгы барабаннарга охшаган. Күрәсең, берүк тубал җәйланмасы кирәк чакта уен коралы, кирәк чакта ашлык чәчү савыты вазыйфаларын да үти алган.

Бу – кызык!

- Параппанның корпусы – агачтан, мембранасы исә эт, ат, кәҗә, сарык һәм сыер тиресеннән ясала.
- Параппанга «бәрү» өчен «токмак» («тукмак» дип тә атыйлар) файдаланыла.
- Чуашларның борынгы бабалары параппанны моннан 1000 еллар элек үк файдаланган дип санала. Әлеге уен коралы ритуаль бәйрәмнәр вакытында һәм сугышчылар тарафыннан кулланылган.
- Традиция буенча, параппанда уйнар алдыннан, инструментны көйләгәндә аны сыра белән эшкәрткәннәр. Шулай иткән очракта, аның тавышы көчлерәк, тирәнрәк һәм шул ук вакытта йомшаграк чыккан.
- Элек-электән параппаннан башка бер генә туй да узмаган. Кайберәүләр бу инструментны туйга дип махсус ясый торган булган. Аны «туй-параппан» дип атаганнар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 370

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+